*Туган телем - иркә гөлем, киңдер сиңа күңел түрем...*

# КҮМӘК КӨЧ

ГОМУМИ РАЙОН ТАТАР ГАЗЕТАСЫ
1930 елдан чыга.
Бәясе ирекле
№ 20 (10712)
Чәршәмбе,
17 май 2017 ел.
(Атнага бер тапкыр чыга)

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫЛАР: 1. УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕ ХӨКҮМӘТЕ (432017, Ульяновск шәһәре, Ленин мәйданы, 1). 2. "ИСКЕ КУЛАТКЫ РАЙОНЫ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРЛӘШМӘСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ (433940, УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕ, ИСКЕ КУЛАТКЫ ЭШЧЕЛӘР БИСТӘСЕ, ПИОНЕРСКАЯ УРАМЫ, 30)

## Герой кайта мәрмәр бюст булып

**12 майда, Иске Кулаткы эшчеләр поселогында, якташыбыз, РФ Герое, Сирия җирендә һәлак булган Рәфәгать Хәбибуллинны искә алу йөзеннән бай чаралар булып үтте. Алар Кореновск шәһәреннән районыбызга Героебызның ике бюстын кайтару уңаеннан оештырылган иде. Бу бюстларның һәрберсенең биеклеге 3 әр метр һәм авырлыклары 3 әр тонна тәшкил итә һәм алар якын арада Рәфәгать Хәбибуллин исемен йөреткән Иске Кулаткы икенче номерлы урта мәктәбе алдына һәм үзе туган Вязовый Гай авылына урнаштырылачаклар.**

(Дәвамы 6 биттә).



## Гаилә – тормыш терәге



**15 май - Халыкара гаилә көне. Бу көн Россиядә 1995 елдан бирле билгеләп үтелә. Әлеге заманда һәр кешегә кайтып сыеныр өчен җылы учак, тыныч почмак булуы кирәк. Ни генә булмасын, кеше үз гаиләсе кочагында ял итә, рухи көч җыя. Районыбыз гомер юлларын матур атлаучы, пар канатлар булып, бер-берсен кайгыртып яшәүче гаиләләр белән горурлана ала. Яңа Зимница авылында яшәүче Мөнирә Исхаковна һәм Хөсәин Мохаррәмович Хәсәновлар 65 ел элек кабызган гаилә учагын сүндермичә, бер-берсенә терәк булып, матур итеп яшәп, әлеге авылның ныклы, үрнәк гаиләләренең берсе булып торалар.**

( Дәвамы 4 биттә).



### ХӨРМӘТЛЕ РАЙОНДАШЛАР, КАДЕРЛЕ ГАЗЕТА УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!

**“Күмәк көч” район газетасына язылу көннәре азаеп бара. Алты айга язылу бәясе бары тик 397 сум 80 тиен генә. Районыбызны, милли газетабызны саклап калыйк, киләсе ярты елда да бергә булыйк дуслар! “Күмәк көч” газетасын рәсмиләштерергә ашыгыгыз.**

## 15 мая – Международный день семьи

**Дорогие ульяновцы! От всей души поздравляю вас с замечательным праздником, прочно объединяющим всех жителей нашего края!**

**Семья – главная опора в жизни каждого из нас, прочный фундамент общества и государства. Ведь любовь и поддержка самых родных и близких людей помогают нам преодолеть любые трудности, вдохновляют на новые свершения, дарят радость и умиротворение.**

**Безусловно, главное богатство любой семьи – это дети. И отрадно, что с каждым годом в Ульяновской области все больше родителей становятся по-настоящему богатыми – многодетными. Сегодня в нашем регионе проживает 10570 многодетных семей, в которых воспитывается почти 35 тысяч детей. Всего же в регионе проживает более 151 тысяч семей, в которых подрастает почти 229 тысяч маленьких ульяновцев. Именно за этими ребятишками – будущее нашего региона. И все, что мы делаем – создаем новые детские сады и школы, учреждения здравоохранения, строим жилье, заводы и ультрасовременные спорткомплексы, - мы делаем именно для них. Особое внимание мы уделяем всесторонней социальной поддержке семей с детьми. Уверен, что общими усилиями мы сможем подарить этим ребятам счастливое будущее.**

**Дорогие земляки, представители всех поколений – дедушки и бабушки, мамы и папы, юные ульяновцы! В этот замечательный праздник желаю вам всего самого светлого и доброго. Пусть ваши родные и близкие будут всегда рядом, дарят вам любовь, заботу и понимание! Крепкого здоровья, счастья, благополучия!**

**С.И. МОРОЗОВ,**
**Губернатор Ульяновской области.**

## Хөрмәтле райондашлар!

Сезне ихлас күңелдән Халыкара гаилә көне белән тәбрик итәбез.

Гаилә гомер-гомергә яшәешнең башлангычы булды. Ул – кешенең төп терәге, җәмгыятьнең рухи сәламәтлеге чыганагы. Гаилә – ул җылылык, мәхәббәт, ышаныч учагы. Аның төп бурычы – балалар үстерү, аларга лаеклы белем бирү, тормышта үз юлларын табарга өйрәтү. Нәкъ менә гаиләдә бала шәфкатьлелек, намуслылык, хезмәт һәм патриотик тәрбиянең беренче сабакларын ала. Гаилә ныклы булса, дәүләт тә ныклы була. Шуңа күрә илебездә гаилә байлыкларын ныгытуга, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән программалар тормышка ашырыла.

Сезгә бу күркәм бәйрәмдә чын йөрәктән иминлек, матур, тату, тигез тормыш, бәхетле көннәр телим. Гаилә учагы тормыш кыенлыкларыннан саклап, үзенә тартып торсын, ата-аналар белән балалар арасындагы мөнәсәбәтләр җылы, ихтирамлы булсын!

**Э.Ә. ГАНЕЕВ,**
**Иске Кулаткы районы Башлыгы, урындагы “Бердәм Россия” партиясе урындагы политсовет Секретаре.**
**В.А. ДЕНИКАЕВА,**
**Иске Кулаткы районы администрациясе Башлыгы вазифаларын вакытлыча башкаручы.**

## 18 май – Халыкара музейлар көне!

**Хөрмәтле музей хезмәткәрләре һәм әлеге тармакта хезмәт иткән ветераннар!**

Халыкара музейлар көне уңаеннан барыгызны да ихлас тәбрик итәбез!

Бүгенге көндә музейлар төрле аудиториягә – яшь буынга, килгән кунакларга, аерым шәхесләргә хезмәт күрсәтә. Ул – милли, тарихи кыйммәтләрне саклау, яшь буынга патриотик тәрбия бирү урыны гына түгел, ә төрле тематик кичәләр, очрашулар оештыру үзәге дә. Музей хезмәткәрләренең югары һөнәри осталыгы, эш сөюе һәм иҗади омтылышы районыбызның мәдәни хәзинәләрен өлкәгә, башка төбәкләргә танытуга ярдәм итә. Сезне тагын бер кат әлеге бәйрәм уңаеннан котлыйбыз, сәламәтлек, актив һәм нәтиҗәле иҗади эшчәнлек, яңа һәм кызыклы проектларны гамәлгә ашыруда зур уңышлар телибез!

**Э.Ә. ГАНЕЕВ,**
**Иске Кулаткы районы Башлыгы, урындагы “Бердәм Россия” партиясе урындагы политсовет Секретаре.**
**В.А. ДЕНИКАЕВА,**
**Иске Кулаткы районы администрациясе Башлыгы вазифаларын вакытлыча башкаручы.**

## Язгы чәчү җаваплы чор



Районыбызның кырларында язгы чәчү эшләре һава торышы мөмкинлекләр биргәнчә бара. План буенча 23176 гектарда каралган мәйданнарның 13117 гектары төрле орлыклар белән чәчелде инде. ИП “Хәбибуллин Р. К.” хуҗалыгында бу эшләр тулаем төгәлләнде. ИП “Ягудин Р. А.” хуҗалыгында да әлеге кампания зур активлык белән үтә һәм алар 800 гектарда (93 %) сабан культураларын чәчүгә ирештеләр.

Быел районда план буенча 8268 гектарда каралган көнбагышның 1675 гектары чәчелде.

Соңгы вакытта яуган яңгырлар кыр эшләрен бераз тоткарладылар. Уңай һава шартлары булганда язгы чәчү районыбызда 10 көндә төгәлләнер дигәнгә тулы гарантия биреп була.

**Р. АРИФУЛЛИН.**

| ПӘНҖЕШӘМБЕ (18.05.) | ҖОМГА (19.05.) | ШИМБӘ (20.05.) | ЯКШӘМБЕ (21.05.) | ДҮШӘМБЕ (22.05.) | СИШӘМБЕ (23.05.) | ЧӘРШӘМБЕ (24.05.) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| + 14 | + 17 | + 22 | + 19 | + 14 | + 15 | + 16 |
| + 9 | + 8 | + 12 | + 8 | + 4 | + 7 | + 7 |

Күмәк көч
№ 20, 17 май 2017 ел.

## ЯҢАЛЫКЛАР



Экология елы кысаларында Россия Президенты администрациясе каршындагы ведомствоара климат үзгәрү һәм тотрыклы үсеш тәэмин итү буенча эш төркеме карары нигезендә 15 майдан 15 июньга кадәр гомумроссия климат атналыгы узачак.

● ● ●

Россия президенты Владимир Путин 2030 елга кадәр икътисади куркынычсызлык стратегиясен раслады, бу хактагы Указы хокукый мәгълүматның рәсми порталында басылды.

● ● ●

РФ хөкүмәте хәбәр итүенчә, 2017 елның маена Президентның "май Указлары" буенча 180 үтәлергә тиеш булган йөкләмәләрнең хәзерге вакытка 90% үтәлгән, дип хәбәр итеп министрлар кабинетының сайтында.



Ульяновск өлкәсендә янгынга каршы профилактик чаралар тормышка ашырыла. Авыл, урман хуҗалыгы һәм табигый байлыклар министрлыгы экспертларының мәгълүматлары буенча янгын куркынычы сезоны башланганнан алып өлкәбездә 70 тән артык янгын очраклары юк ителгән. Янгын сүндерүдә барлыгы 214 кеше һәм 87 берәмлек техника җәлеп ителгән. Барлык янгыннар да ачыкланган көнендә дә сүндерелгән.

● ● ●

Үткән атнада Ульяновск өлкәсенең бюджетыннан халыкка социаль ярдәм күрсәтүгә якынча 100 миллион сум акча бүленгән. 65 меңнән артык кешегә ташламалар бирелгән.

● ● ●

2017 елның 4 аенда Ульяновск өлкәсе казнасына 652 миллион сумнан артык өстәмә акча керде. "Без мөмкин кадәр чыгымнарны киметергә һәм өлкә бюджетының керем елешен арттыру эшләрен көчәйтергә тиешбез. Бүгенге көндә региональ Хөкүмәте өчен нәкъ менә бу мәсьәлә иң актуаль булып санала", - дип ассызыклады Ульяновск өлкәсе Губернаторы Сергей Морозов.

**19 май - Бердәм чисталык һәм пөхтәлек көне**

# Төзекләндерүдә бердәм булыйк!

Губернатор С. И. Морозов инициативасы буенча Ульяновск өлкәсендә киңәйтелгән төзекләндерү айлыгы бара, ул 1 июньгә кадәр дәвам итәчәк.

Безнең районда да һәр чәршәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә тирә – якны җыештыру, чистарту дәвам итә. 19 май - өлкәдә Бердәм чисталык көне итеп игълан ителгән. Шуңа әзерлек бара.

Иске Кулаткы эшчеләр бистәсенең Пионерская урамында урнашкан хезмәт ветераннарының мемориаль үзәген төзекләндереп тору өчен шушы тирәдә эшләп торган кибет, эшкуар, аптека, Саклык банкы, Россия Пенсия фондына һ.б. хезмәт коллективларына беркетеп чыктылар. Хәзер һәрбер хезмәт ветераныныӊ истәлекле тактасы һәм аның төбендәге



мәйданчыгын да чистарту, чәчәкләр үстерү буенча махсус коллективы бар.

Алар андагы тәртипне, матурлыкны булдыру өчен җаваплы булачаклар. Шушы аллеялар аша үтү басмалары да өч – дүрт урында плитәләрдән салына. Моны инде җәяүлеләр өчен уңай булсын дип "Транстехсервис" предприятиесе эшли.

Һәрбер коллективның үзенә беркетелгән мәйданчыклары бар. Анда һәрчак тәртип, пөхтәлек булдырып тору зарур.

**Г. АХТӘМОВА,**
**район архитекторы.**

# Развитие гражданского общества

В Ульяновской области подвели итоги первой сессии Совета при Губернаторе по развитию гражданского общества и правам человека.

В мероприятии приняли участие глава региона Сергей Морозов, члены регионального Правительства, председатели Общественных советов при исполнительных органах государственной власти, представители некоммерческих организаций.

«Мы живем в государстве, где каждый человек наделен определёнными свободами и правами. Но, к сожалению, не все жители региона знают о них и умеют их защищать. Поэтому наши общественные объединения, а также данный Совет, наделенный большими контрольными функциями, должны быть главными помощниками гражданам в этой деятельности. Кроме того, считаю, серьезного внимания требует вопрос усиления общественного контроля. Мы должны активней поддерживать инициативы наших граждан, активней откликаться на их критические замечания и принимать необходимые и, порой, жесткие решения по устранению всех нарушений прав и свобод наших граждан. Сейчас для нас также важно принять закон об общественном контроле. В его разработке должны принимать участие институты гражданского общества», – сказал Сергей Морозов.

Как отмечает председатель Совета при Губернаторе Ульяновской области по развитию гражданского общества и правам человека Венера Браташова, всего в мероприятиях первой сессии в 2017 году приняло участие более 150 представителей общественных советов, общественных палат, некоммерческих организаций, инициативных групп. Так, члены Совета посетили Сурский, Карсунский и Базарносызганский районы, где было организовано и проведено более 20 рабочих площадок.

«Целью данной сессии стали сбор и подготовка информации о положениях дел в вопросах соблюдения прав и свобод человека и гражданина, содействие правовому просвещению граждан, развитию взаимодействия общественных объединений с органами государственной власти. В муниципальных образованиях мы посетили учреждения социальной сферы, где проверили качество предоставления социально–государственных услуг, уровень обслуживания. Мы проводили бесплатные личные консультации по нотариальным, юридическим вопросам. Членами совета проводились личные приёмы граждан, где были рассмотрены различные вопросы», – сказала Венера Браташова.

В ходе мероприятия заместитель Губернатора Ольга Никитенко доложила о системе поддержки на территории региона социально ориентированных НКО. Напомним, в целях развития некоммерческого сектора в 2011 году была утверждена государственная программа «Гражданское общество и государственная национальная политика Ульяновской области». Одна из основных задач утверждённой программы – создание условий для дальнейшего становления некоммерческих организаций и обеспечение их эффективного участия в социально-экономическом развитии региона.

«Проведению грантовых конкурсов среди НКО следует уделить особое внимание. В текущем году средства, выделяемые из областного бюджета на эти цели, будут увеличены с 9 до 12 миллионов рублей. Кроме того, в регионе отдельно будет проведён конкурс на предоставление субсидий среди проектов религиозных организаций и национально-культурных автономий, направленных на укрепление межэтнического и межконфессионального мира и согласия. Сумма средств на данное направление составит порядка семи миллионов рублей. Ожидается, что общее количество благополучателей в текущем году составит не менее 20 тысяч жителей нашего региона», – сказала Ольга Никитенко.

С докладом о соблюдении прав граждан на территории Ульяновской области выступил руководитель Центра оказания правовой помощи населению при юридическом факультете Ульяновского государственного педагогического университета имени И.Н. Ульянова, заведующий кафедрой гражданского права Юрий Гриценко. По его словам, особенно важным направлением в сфере защиты прав граждан должна стать реализация мероприятий, направленных на повышение юридической грамотности населения.

«Ключевая цель нашего центра – оказание бесплатной юридической помощи и повышение уровня знаний наших учеников. За текущий год к нам обратилось 72 человека, 37 из которых требовалась консультация в сфере трудового права. Это свидетельствует о том, что у нас очень много нарушений в этой среде. Главная причина – элементарное незнание как гражданами, так и работодателями трудового законодательства, а также неправильное трактование закона», – сказал Юрий Гриценко.

**Для справки: Получить первичные консультации юриста Государственного юридическое бюро Ульяновской области можно по бесплатному телефону «горячей линии» (8–800–100–13–84). Кроме того, в регионе запущен проект по оказанию юридической помощи – сайт «бесплатнаяюрпомощь.рф».**

## Коррупциягә каршы көрәш атналыгында

Безнең Иске Кулаткы районында җәмгыятьтә коррупциягә каршы көрәш алып бару буенча төрле чаралар даими рәвештә үтеп тора. Мәсәлән, бишенче региональ "Антикоррупция инициативалары атналыгы" (24-28 апрель) кысаларында гына 20 чара уздырылды һәм үз эченә 2 меңгә якын кешене берләштерде.

Әлеге атналыкта халык арасында коррупциягә каршы Кодексны тарату эшләре алып барылды. Алар масса чараларында (традицион җиңел атлетика кроссында) кәгазь форматларында һәм социаль челтәрләрдә электрон формаларда таратылдылар. Шулай ук "Коррупция тукта!" акциясе кысаларында буклетлар һәм белешмәлекләр җәелдерелде.

Ә инде районыбызның мәктәпләрендә традиция буенча "Коррупция тукта!" дигән темага рәсемнәр конкурсы һәм класс сәгатьләре оештырылды. Класс сәгатьләрендә Иске Кулаткы районының депутатлар корпусы һәм коррупциягә профилактика буенча Җәмәгать Советы, җәмәгать контроле, Гаделлек Палатасы әгъзаларына да катнашырга туры килде.

Җирле үзидарә органнарының сотрудниклары өчен шулай ук практик семинарлар үткәрелде һәм алар тарафыннан башлангыч фермер хуҗалыкларында (Р. Ф. Усманов, Г. Ш. Тимушев) Ульяновск өлкәсенең бюджетыннан бүленеп бирелгән акча средстволарының максатчан кулланышына тикшерүләр алып барылды.

Атналык барышында халыкның мөшгульлек үзәге һәм индивидуаль предпринимательләр, эш бирүчеләр белән түгәрәк өстәл артында "Легаль хезмәт- киләчәкнең нигезе" дип исемләнгән утырыш булды.

Бишенче региональ "Антикоррупция инициативалары атналыгы" кече һәм урта бизнесның үзара бәйләнешенә юнәлдерелгән иде һәм шуңа күрә кайбер чаралар предпринимательлек үсеше Үзәге белән бердәмлектә үтте. Бу атналык кысаларында район администрациясе Башлыгы И. А. Аблязов гражданнарны, предпринимательләр Ф. М. Шафиеваны, А. Р. Кадерованы шәхсән үзе кабул итте һәм аларга консультацияләр бирде.

Атна барышында шулай ук предпринимательлек вәкилләре өчен кайнар линия һәм укучылар белән аралашу да оештырылды.

**Альбина МОСТАФИНА,**
**Иске Кулаткы район администрациясе аппаратының җитәкчесе.**

**ИЗВЕЩЕНИЕ О ПРОВЕДЕНИИ СОБРАНИЯ О СОГЛАСОВАНИИ МЕСТОПОЛОЖЕНИЯ ГРАНИЦ ЗЕМЕЛЬНОГО УЧАСТКА**

Кадастровым инженером ОГУП БТИ Вилковым Андреем Олеговичем, р.п. Новоспасское, ул. Механизации, д.1, контактный телефон 8 (84238) 2-11-38, адрес электронной почты art_vilkov@mail.ru, N квалификационного аттестата 73-13-197, в отношении земельного участка с кадастровым номером 73:15:040101:1196 , расположенного обл. Ульяновская, р-н Старокулаткинский, р.п. Старая Кулатка, ул. Пионерская, дом 26 А, выполняются кадастровые работы по уточнению границ и (или) площади земельного участка.

Заказчиком кадастровых работ является: Якупов Марс Мунирович.

Собрание по поводу согласования местоположения границ состоится по адресу: Ульяновская область, р.п. Старая Кулатка, ул. Пионерская, 30 (ОГУП БТИ) 19.06.2017г. в 10 часов 00 минут.

С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: Ульяновская область, р.п. Старая Кулатка, ул. Пионерская, 30 (ОГУП БТИ) .

Требования о проведении согласовании местоположения границ земельного участка на местности принимаются с 16.05.2017г. по 19.06.2017г., обоснованные возражения о местоположении границ земельного участка после ознакомления с проектом межевого плана принимаются с 16.05.2017г. по 19.06.2017г., по адресу: Ульяновская область, р.п. Старая Кулатка, ул. Пионерская, 30 (ОГУП БТИ).

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границ: КН № 73:15:040101:245 (Ульяновская обл., р-н Старокулаткинский, р.п. Старая Кулатка, ул. Пионерская, д. 26).

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы, подтверждающие права на соответствующий земельный участок.

18 мая - Международный день музеев

# Увековечил историю родного края



Участников Великой Отечественной войны год от года становится все меньше. Безжалостные годы вырывают из жизни то одного, то другого героя.

Памяти одного из них посвящается эта статья.

Хамзя Абдулхакович Аблязов родился в бедной, крестьянской семье. Это были тяжелые голодные годы. Чтобы выжить самому и помочь семье, он будучи учеником 9-го класса ходил зимой на лыжах, а летом пешком за 15 км. от Старой Кулатки в село Кармалей учительствовать, где он обучал учеников различного возраста грамоте. А ученики были порою старше самого учителя ЛИК БЕЗа. Поражаешься и сейчас той недетской мудрости этого подростка, обучавшего молодежь не только грамоте, но и азам военного дела, проводя игры среди детей с марш-бросками, разведкой, маскировкой, атаками.

Шла Великая Отечественная война. Немцы рвались к Волге. Будучи пламенным патриотом, Хамзя Аблязов неоднократно требовал отправки его добровольцем на фронт. Но ему не было еще 18 лет и он получал в военкомате постоянные отказы. Осенью 1942 г. вопреки всему он добровольно ушел на фронт. Его зачислили в Рязанское пехотное училище на курсы пулеметчиков. Ввиду резкого ухудшения положения на фронтах, курс обучения молодых пулеметчиков сократили и направили необстрелянных бойцов на передовую в состав центрального фронта. Юный боец был первым номером пулеметного расчета и с первых дней боев попал на Курскую дугу, где участвовал в ожесточенных сражениях с врагом. Здесь он получил тяжелое осколочное ранение в бедро и контузию головы. За проявленную отвагу в боевых действиях Хамзя Абдулхакович был награжден несколькими боевыми наградами. После длительного лечения в госпиталях и реабилитации он был направлен для выполнения особого задания в составе специализированного правительственного батальона в Иран командиром отделения автоматчиков для сопровождения по Land lise составов с американской военной техникой, и продовольствием из Ирана в Советский Союз, и одновременно был переводчиком , т.к. он знал арабский шрифт, читал Коран, и знал каноны мусульман. Имеется фото, сфотографированы три товарища - фронтовика. При продвижении железнодорожных составов приходилось отражать нападения диверсантов. При очередном отражении нападения диверсантов на состав он был ранен и награжден правительственной наградой. Пройдя вместе со своим народом тяготы и лишения войны, он демобилизовался в 1946 г. и вернулся в родное село. Началась его трудовая жизнь в Старой Кулатке.

Он был назначен инспектором в РОНО. Трудился Хамзя Абдулхакович и обучался заочно в Ульяновском педагогическом институте, который закончил с отличием. Вскоре Старокулаткинский Райком назначил его директором единственной в районе средней школы. И это решение Райкома было своевременным и верным. Здание находилось в ужасном состоянии. Сорванные с петель двери, разбитые окна, а печи непригодные к отоплению. Молодой директор развернул бурную деятельность по приведению ветхих зданий школы в надлежащее состояние. Денег никто не выделял, так как их не было. Топить здания было нечем - не было дров. Пальцы учащихся и чернила замерзали от холода. Помощи ждать было неоткуда. Молодой директор начал организовывать из ребят-старшеклассников отряды на заготовку дров за 12 км. от села. Они вместе со старшеклассниками работали по пояс в снегу откапывали от снега деревья, распиливали и укладывали бревна в штабеля. С транспортом помог райисполком. Школа начала отапливаться. Холод был побежден. Количество учащихся 8-9 классов возросло. Средняя школа уже имела в своем составе несколько зданий , и все они нуждались в отоплении и капитальном ремонте. Молодежь из сел района стекалась в среднюю школу для получения прочных знаний и аттестата, чтобы дальше продолжать образование. Для обустройства быта молодежи директор видел необходимость постройки интерната. Он позаимствовал нивелир у землеустроителей района и собственноручно начертил план фундамента будущего интерната. Старшеклассники вместе с директором рыли траншеи и заполняли их бутовыми камнями, которые они же возили с карьера. Имеется фото, где директор и ученики роют и закладывают фундамент интерната. Общими усилиями интернат для проживания приезжих из далеких сел ребят был построен. В интернате была открыта прекрасная столовая. Ребята проживающие в интернате получали полноценное питание. Могу смело утверждать, что одним из прогрессивных начинаний молодого директора явилось то, что впервые в области он организовывал летние трудовые лагеря для учеников. Расположение трудового лагеря выбиралось и готовилось заранее. Возле леса, недалеко от водоема строилось летнее сооружение, назначались дежурные педагоги, которые следили за организацией труда, питания и отдыха детей и несли персональную ответственность за их безопасность. Старшеклассники пропалывали посевы кукурузы, картофеля, свеклы, оказывая помощь сельским труженикам. Лагерь Труда и Отдыха, созданный при школе, многократно занимал первые места по результатам областных соревнований среди лагерей. Несколько раз ездили в Москву на ВДНХА. Опыт работы Лагеря Труда и Отдыха приезжали изучать из Татарстана и многих регионов России. Ученики вспоминают этот период своей жизни с благоговением.

За период работы директором Старокулаткинской средней школы с 1951 г. по 1964 г.г. Аблязов Х.А. внедрил много новшеств, так например, выпускники средней школы получали вместе с аттестатом зрелости водительские права на вождение авто, тракторов, свидетельство о прохождении курсов швеи. Выпускникам школы Хамзя Абдулхакович организовывал группы из учащихся-механизаторов. Они летом работали на полях совхоза. Часть урожая совхоз отдавал школе для столовой. На пустыре вокруг школы вместе с ребятами был высажен фруктовый сад, саженцы для которого были привезены из питомника г.Хвалынска. Фруктовые деревья давали прекрасный урожай для школьной столовой. Была построена теплица для круглогодичной витаминизации столов учеников и биологических опытов. В тот период обучалось около 1,5 тыс учеников. Учительский коллектив составлял 75 чел.

Учительских кадров в районе не хватало. И к большой заслуге Аблязова Х.А. надо отнести факт открытия и организации Техникума на базе Старокулаткинской средней школы при содействии зав. ОБЛОНО Борисова А.А. В течении нескольких лет техникум готовил учительские кадры для района. Многие выпускники техникума оставались работать в школах Старокулаткинского района.

За большие заслуги в деле обучения и воспитания подрастающего поколения Аблязов Хамзя Абдулхакович был удостоин звания Заслуженный Учитель России.

В последующем, Хамзя Абдулхакович работал в райкоме партии заведующим отделом агитации и пропаганды. Работал также директором Старокулаткинской восьмилетней школы.

Историк - Аблязов Х.А. любил свою Родину! Свой родной край, свою родную Кулатку! И понимал необходимость создания и открытия историко - краеведческого музея Старокулаткинсого района. Воплощению в жизнь своей идеи - создания музея истории района он посвятил всю свою дальнейшую жизнь. В течение многих лет изо дня в день он скрупулезно собирал материалы о выдающихся людях Старокулаткинского района: об известных земляках района: революционерах, участниках Гражданской и Отечественных Войн, ученых - земляках, передовиках народного хозяйства. В музее были собраны уникальные экспонаты и ценные документы, материалы, которые могли бы украсить даже столичные музеи. Например: денежные купюры времен Екатерины II, серебряные монеты России различных эпох, старинные украшения и предметы национальной одежды, макеты крестьянских изб, строений, предметы домашней утвари крестьян. Он собирал материалы по разным городам, работая в архивах Москвы, Саратова, Баку, Свердловска, Бухары и др. Все это годами он делал совершенно безвозмездно, не рубля не получая за свои труды, используя личное время и средства. Но многие не понимали и не ценили его труд. Однажды он ужаснулся, увидев среди ненужного хлама школьного двора важнейшие ценнейшие документы лежащими в лужах.



У создающегося музея своего помещения не было. Для размещения экспонатов Директору отвели заброшенное неприспособленное здание, которое впоследующем неоднократно пришлось «отвоевывать» у местного начальства. В течение 15 лет происходило мытарство музейных ценностей по различным брошенным домишкам, которые приходилось приспосабливать и приводить в более или менее надлежащий вид. Ценнейшие экспонаты в связи с отсутствием постоянного законного места не раз приходилось переносить из одной «комнатушки» в другую. Между тем из других сел района и области стали приезжать учителя со своими учениками, колхозники, парторги. Целые делегации из других сел района и области приезжали ознакомиться с материалами и экспонатами музея. Наконец начальство района осознало необходимость строительства отдельного здания для музея. Которое и было возведено и в торжественной обстановке и открыто в центре поселка. Музею было присвоено имя его создателя. Об истории Старокулаткинского района и создании музея им была написана книга «Ступени роста»

Нет уже в живых создателя историческо-краеведческого музея Аблязова Хамзи Абдулхаковича. Но память о нем хранится в его делах, его учениках, и в сердцах односельчан. Он принадлежал к когорте тех людей о которых можно сказать словами В.Маяковского: «Гвозди бы делать из этих людей, крепче бы не было в мире гвоздей» .

# Күңелендәге тойгылары рәсемнәрендә чагыла

Кешенең иң матур истәлекләре, иң изге хыяллары, иң беренче шатлык – куанычлары аның балачагы яки үсмер, яшьлек чоры белән бәйләнгән була. Менә шушы матур истәлекләр арасында шактый урынны мәктәп, балачак дуслары һәм, әлбәттә инде, укучылар алып тора. Иң беренче мәктәп бусагасын атлап кергән көннән алып, зур тормышка озатып соңгы кыңгырау чыңлаган көнгә кадәр бала белән һәрчак янәшәдә аның Укытучысы атлый. Ул аны белем дөньясына алып керә, яхшыны яманнан аерырга, хезмәт һәм иҗат шатлыгын тоярга, аңардан шәхес тәрбияләргә бөтен көчен куя.

Укытучы!!! Нинди тирән мәгънә ята бу сүздә. Үзенең көчен кызганмыйча, үз баласыдай саклап, яклап йөрүче син – Укытучы! Авыр чакларда беренче булып ярдәм итүче дә, каршылыкларны да җиңүче



син – Укытучы!

Укытучы барлык һөнәрләргә юл ачучы. Күпкырлы, эзләнүчән, тәрбияче, могҗиза кылучы. Чын укытучы – бәхетле кеше, чөнки аның кулында бөтен кешелек бәхете.

Минем әнием бала чактан ук укытучы гаиләсендә үскәнгә күрә, укытучы һөнәрен сайлап алган. Үсмер чагы бик авыр елларга туры килсә дә белемгә омтылган. Сүзем Иске Кулаткы урта мәктәбендә бар гомерен балалар укытуга багышлаган Нажия Абдрахман кызы Шамазова – Аблязова турында бара. Ул 1926 елның 18 сентябрендә Мәләкәс шәһәрендә туган, шунда ук укытучы белгечлеге алган. 1947 елда югары белемле укытучы кызны Иске Кулаткы районына балаларга белем бирергә юллыйлар. Рус теле һәм әдәбиятын татар балаларына укыту, дөрес итеп язу, сөйләшергә күндерү җиңел булмый, әлбәттә. Тик ул моңа бар көчен, сәләтен куя, һәм укучыларының югары уку йортларына китеп рус теле һәм әдәбияты укытучысы һөнәрен сайлаулары күп нәрсәне аңлата.

1948 елда Бөек Ватан сугышыннан Җиңү яулап кайткан егет Хамзә Абдулхак улы Аблязов белән гаилә коралар. Әтием Хамзә Абдулхакович турында югарыдагы мәкаләдә язып чыктым.

Әниебез Нажия Абдрахмановна күпкырлы талант иясе һәм укымышлы шәхес булганга да ахры үзенә дә, укучыларны да, ата – аналарны да, коллективны да җәлеп итә алган. Ул гына түгел безне, балаларын да дөрес тәрбия биреп, яхшы укырга, кеше булырга күндерә алган. Ул үзе дә китап укырга яратты һәм бездә дә китапка мәхәббәт уятты. Ул бик кызыклы, театраль - иҗади кеше генә түгел, рәссам сәләтенә дә ия булып торды. Әлеге талант анарда яшь чакта ук булган тик укыту, өй мәшәкатьләре белән рәсем ясарга аның вакыты калмаган. Дүрт баласын кешелекле итү, һәркайсыбызга һөнәр үзләштерүдә ярдәм итү, укыту эшеннән башка җәмәгать эшендә актив катнашу аркасында үз талантын үстерә алмаган ул.

Әнием лаеклы ялга чыккач, мин аны сәнгать мәктәбендә укучы кызым белән бергә диңгезгә ял итәргә алып бардым. Кызым Гүзәл Амирова рәссам сәнгатен бик яратып өйрәнде. Һәрвакыт үзе белән буяулар һәм пумалалар алып йөри иде.

1992 елның җәй кичендә Туапсе шәһәренең Интал бухтасында әнием, кызым Гүзәлгә сокланып рәсем ясарга кереште. Шул кичтән соң 20 ел буена әни рәссам булып китте, ясаган саен мавыга барды һәм 85 яшенә кадәр һаман кулына пумаласын алып җае чыккан саен рәсем ясады. Аның инде 50 дән артык сәнгать әсәре бар. Ул үзенең иҗади шатлыгы белән, гомеренең иң яхшы мизгелләре белән уртаклашты. Иске Кулаткысына да күрсәтәсе килде. Шуңа күрә без аның күргәзмәсен әтиебез булдырган крайны йөрәнү музеенда ясамакчы булдык. Бу эштә безгә Ульяновск өлкәсенең татар милли – мәдәни автономиясе, шәхсән Р.Ф. Сафин да ярдәм итте. Иске Кулаткы музей директоры Р.М. Байбикова да, район мәдәният һәм сәнгать идарәсе дә, район администрациясе дә ачык йөз белән каршы алып, оештырырга ярдәм иттеләр. Бүген инде әниебезгә 91 яшь тулды, шөкер хәерле аңында, Иске Кулаткысын бер дә теленнән төшерми. Ә әтиебез 2002 елның 2 нояберендә инде вафат булды. Аның якты истәлеге безнең күңелләрдә мәңгегә саклана.

**Рәйсә АМИРОВА – АБЛЯЗОВА, Санкт - Петербург.**

15 май - Халыкара гаилә көне

# Гаилә – тормыш терәге

Мөнирә апа һәм Хәсәин абый күп балалы гаиләләрдә туып, яшьли тормыш арбасына җигеләләр. Сугыш елларының бар авырлыкларын үз җилкәләрендә татып үсәләр. Хәсәин абый авыл мәктәбенең VII сыйныфын тәмамлап, 10 яшеннән колхозда хезмәт итә башлый. Яшьтәшләре белән бергә утын, су ташуда, терлеккә азык әзерләүдә катнаша. Ул гомерен авыл белән бәйли. Уңган, тырыш, “алтын куллы” булганга, озак еллар балта остасы булып хезмәт итә. Авыл клубын, терлекчелек комплексын, Яңа Зимница урта мәктәбен төзүдә аның өлеше байтак. Нинди эшкә алынса да, Хәсәин Мохаррәмович барысын да булдыра, күңелен биреп эшли. Тырыш хезмәте өчен күп тапкыр Почет грамоталарына, Рәхмәт хатларына, медальләргә, “Хезмәт ветераны” исеменә лаек була.

Мөнирә Исхаковна – гаилә учагын саклаучы, уңган-булган хуҗабикә, балаларына – олы йөрәкле әни. Эштә дә өлгер була. Авыл колхозында төрле эшләрдә карусыз хезмәт итә. Хезмәттәге уңышларын бәяләп, аңа төрле билгеләр, бүләкләр тапшырыла. Үзенең эшен пөхтә итеп үтәп, һәр нәрсәне җиренә җиткерә. Тормыш иптәше белән бергә, дус-тату яшәп, үз көчләре, үз тырышлыклары белән тормыш күтәреп, хуҗалыкта кош-корт үстереп, мал-туар асрап, кызлары Рәбиягә, Рушаниягә һәм уллары Рафикка, Тәүфыйкка, Ринатка гомер бүләк итәләр. Алар да ныклы тәрбия алып, әти-әниләренә лаеклы булып үсәләр. Төрле һөнәрләр үзләштереп, үз гаиләләрен коралар.

Шулкадәр бала тәрбияләп, еллар буе алар белән мәш килеп, хуҗалыкны алып барган хатын-кызны үз борчуларына чумган апа итеп күз алдына китереп булмый. Анарга карап, “сөбханалла” гына диясе кала! Балалары өчен янып яшәгәнгә күрә, аларга дөрес тәрбия биргәнгә, Мөнирә Исхаковна II нче дәрәҗәле “Аналык” медале белән бүләкләнә. Аның турында авылдашлары да бары тик җылы сүзләр әйтәләр һәм ихтирам итәләр.

Хәсәин абый лаеклы ялда булса да, авыл тормышында актив катнаша. Яшь буынга патриотик тәрбия бирүдә зур тырышлык куя. Авылда үткәрелә торган чараларда аның катнашы белән үтә. Хәсәин Мохаррәмович гомеренең бер генә көнен заяга уздырмый. Ул сәнгатькә гашыйк - авылның оста гармунчысы. Кече яшьтән үк гармун моңына гашыйк булып, авылдашларын матур чыгышлары белән шатландырып, гармун уйнауда зур осталык күрсәтә. Әлеге сәләте турында төрле елларда бирелгән Рәхмәт хатлары һәм бүләкләр сөйли.

Бүгенге көнгә Мөнирә Исхаковна һәм Хәсәин Мохаррәмович Хәсәновлар үзләрен бәхетле итеп санайлар. Аларның 10 оныклары һәм 7 оныкчалары бар. Кече уллары Ринат, килене Зөлфия белән бер сүздә булып, бер-берсен аңлап, тату тормыш итәләр.

Хәсәновлар шатлыкта да бер-берсенә терәк булып яшиләр. Мөгаен, бер-береңнең күңел халәтен тоеп, бер күз карашыннан аңлашып, үзара ихтирам итеп яшәгәндә генә, алтмыш биш һәм аннан да күбрәк ел бергә яшәп була.

Мөнирә Исхаковна һәм Хәсәин Мохаррәмович Хәсәновлар үрнәк тормыш алып барулары өчен “Ульяновск өлкәсенең алтын гаиләләре” номинациясендә регион Башлыгы С.И. Морозовның “Ел гаиләсе” премиясенә лаеклы булдылар.

Без дә аларны әлеге уңышлары белән котлыйбыз һәм Халыкара гаилә көне уңаеннан ихластан котлыйбыз. Гаилә ныклыгын саклый алганыгыз, мәхәббәткә изге итеп карагангыз өчен рәхмәт белдерәбез.

**Ә. ЯФАРОВА.**

# Без онытырга тиеш түгел!



“Сугыш турында балаларга укыйбыз” Халыкара акция кысаларында, Җиңү көне алдыннан, район китапханәләрендә һәм мәктәпләрдә Бөек Ватан сугышы турында иң яхшы әдәби, нәфис әсәрләр кычкырып укылды. Иске Кулаткы районының үзәк балалар китапханәсе хезмәткәре Г.Х. Бекирова әлеге акцияне Иске Кулаткы беренче номерлы урта мәктәбендә II «Б» сыйныф укучылары белән үткәрде. Балаларга Лев Кассильнең “Рассказ об отсутствующем» әсәрен укыды.

Ә инде китапханәче Ә.Р. Рәхмәтуллина әлеге мәктәпнең IV “Б” сыйныфында Сусанна Георгиевскаяның “Галина мама” әсәрен укыды.

“Сугыш турында китаплар укыйбыз” исемле флешмобта Иске Кулаткы икенче номерлы урта мәктәбенең VI `һәм VII сыйныфлар укучылары катнашты. Китапханәчеләр, уку эше буенча директор урынбасары, тарих һәм әдәбият укытучылары Александр Твардовскийның шигырьләрен һәм сугыш турында башка әсәрләрне укыдылар.

Әлеге акцияләр укучыларда Бөек Җиңү һәм сугыш турында белемнәрен арттыру, гражданлык һәм патриотик хисләр, туган җиргә, милләткә карата мәрхәмәтлелек, горурлык хисләре тәрбияләү, китап укуга кызыксыну уяту максаты белән оештырылды.

**Наилә УЛЮКАЕВА,**
**үзәкләштерелгән китапханәләр челтәре директоры.**

# Табигатебезне бергәләп саклыйк!

21 апрель кичендә Вязовый Гай авылы китап сөючеләре өчен чын бәйрәм булды. Китапханә мөдире Бәширова Халидә Яхьевна «Библиотен» кысаларында кызыклы гына чара үткәрде. 2017 ел – Экология елы дип игълан ителгәнгә күрә, әлеге чара шул темага багышланган иде. Биредә мәктәп укучылары да, олылар да катнашты.

Халидә Яхьевна иң элек табигать – һәрберебезнең өе, аны һәркем сакларга һәм якларга тиешле турында сөйләде. Аннан соңын мөһимлеге, авылыбыздагы су чыганаклары – Терешка елгасы, кизләүләр, аларны чүп-чардан чистарту, тиешле дәрәҗәдә тоту, пычратмау – төп бурычыбыз булуы турында әңгәмә корылды. Экологик викторина да балаларны бик кызыксындырды, барчасы да бик теләп катнашты. “Кызыл китап”та булган үсемлекләрнең күбесе безнең якларда да үсә һәм табигатьне саклауга без дә зур өлешебезне кертә алабыз. Викторинада җиңүчеләргә бүләкләр тапшырылды. Шулай ук катнашучылар да игътибарсыз калмады.

Авылдышыбыз Марифә Иксанова бик матур шигырьләр иҗат итә. Әлеге кичәдә ул үзенең “Табигатьне саклыйк!» дигән шигырен кунакларга сәнгатьле итеп укыды. Кичә азагында бәйрәмдә катнашучыларны Халидә Яхьевна үзе әзерләгән тәмле-тәмле ризыклар белән сыйлады. Барысы да өйдә үстерелеп, өйдә әзерләнгән экологик чиста ризыклар иде. Хуҗалыкта үстергән тавык белән бәрәңгене, төрле -төрле салатларны, бәлешләрне кунаклар бик яратып ашады. Тәмләп ашагач, балалар рәхәтләнеп күңел ачтылар, биеделәр, ял иттеләр.

Шундый күңелле бәйрәм кичәсен оештыручы Халидә Яхьевнага рәхмәтләребезне белдерәбез һәм эшендә уңышлар, иҗади күтәренкелек теләп калабыз.

**Сания ЮСУПОВА.**
**Вязовый Гай авылы.**

# Ватаның белән горурланып яшә



Бөек Җиңү бәйрәме алдыннан районыбызда бик күп тантаналы, истәлекле чаралар үтте. Аларның һәркайсы өлкәннәрнең дә, яшьләрнең дә күңелендә уелып калды.

Россия Пенсия фонды һәр ел пенсионерлар Союзы белән берлектә Иске Кулаткы беренче номерлы урта мәктәбенең кадетларын сугыш чоры балалары белән очраштыра. Алар бергәләп күңел ачалар, бер-берсе белән фикер алышалар. А.В. Нәүмәтуллин һәм Д.Ш. Усманова җитәкләгән VII нче сыйныф укучылары бу чарага бик теләп әзерләнгәннәр иде. Җырлар, шигырьләр өйрәнеп, өлкәннәр алдында чыгышлар ясадылар. Ә пенсионерлар Союзы рәисе Р.Я. Мусина һәм Россия Пенсия фондының Иске Кулаткы идарәсе җитәкчесе Ш.С. Курамшин сугыш елы балаларына олы хөрмәт күрсәтеп, Бөек Җиңү белән котладылар, якты теләкләрен җиткерделәр. Сугыш чорын күргән, авырлыкларын татыган балалар, хәзер инде чал чәчле абый – апалар да төшенкелеккә бирешмичә балаларга үзләренең осталыкларын күрсәттеләр. Хезмәт ветераны Р.А. Ягодин гармунда искитәрлек итеп тезмә моңнар башкарды, Ө.Ф. Ризванов һ.б. җырлар бүләк иттеләр.

Р. Я. Мусина балаларга патриотизм, туган ил белән горурланып яшәүнең мәгънәсен бик матур итеп аңлатты:

- Патриот дигәннән мин туган илне, үз халкыңны яратуны, Ватанга мәхәббәтне күз алдына китерәм. Ватан ул минем өчен әти - әни, синең хәлеңне белүче күршеләр, өй каршында үскән алмагач, туган йорт, туган мәктәп... Ничек инде ул туган авылыңның салкын чишмәләрен, яшел болыннарын, калын урманнарын, чут-чут килеп сайраучы сандугачлы талларын яратмаска мөмкин соң?! Һәр кеше үз халкы, үз милләте, үз Ватаны белән горурланырга тиеш, дип уйлыйм. – диде. Балалар шуны аңлап калсалар иде дип йөрәгендәге иң изге теләкләрен җиткерде. Аннары район Башлыгы Э.Ә. Ганеев ярдәме белән әзерләнгән мул чәй өстәле артына утырып, бергәләп чәйләр эчтеләр. Балалар да , өлкәннәр дә канәгать булып калдылар.

**М. САНАТУЛЛИНА.**

Дин, әхлак һәм вөҗдан ирегә

# Дини гыйлем бәйрәмендә

Гыйлем ике төрле: дөньяви гыйлем һәм ахирәт гыйлеме. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) безгә шушы ике гыйлемне дә тигез күрергә кушты. Әти-әниләр өстендә булган хакларның да берсе шул: алар баласына дөньяви һәм дини гыйлемне өйрәтергә тиеш. Шулай итеп, дини белем бирү – әти-әни өстендә булган бик мөһим бурыч. Әгәр ата-ана баласына дини гыйлемне бирмәсә, аның Аллаһ каршындагы бер бурычы үтәлмәгән була. Үзе белмәсә, ул башка кешегә барып, баламны намаз укырга өйрәт, дип сорарга тиеш.

Аллаһыбызга бик шөкер, безнең мәчетләребездә, мәдрәсәләребез дә дини гыйлем бирү бик яхшы оештырылган. Район Башлыгы Э.Ә. Ганеев моңа зур әһәмият бирә. Анда сәләтле, кулларында таныклыклары булган мөгаллимәләр теләгән һәр кешегә дини гыйлем бирәләр, намаз укырга да өйрәтәләр һәм башка барлык дини кануннарны күңелләребезгә иңдерәләр.



13 май көнне "Җәмигъ" мәчетендә шушы изге урында төрле чорда дини белем алган шәкертләр җыелган иде. Бу көнне мөгаллимә Мәйсәрә хаҗия Шәфиева бер төркем шәкертләренә Коръән укырга өйрәнүләре, намаз кагыйдәләрен үзләштерүләре турында таныклыклар тапшырды. Әлеге чара дини хәдисләр белән уралып барды. Мәйсәрә Хәсәновна хәдисләрнең төрлесен укып мәгънәсен аңлатты.

Шулай ук чыгарылыш төркемнен тәбрикләү, мөгаллимә тарафына рәхмәт сүзләре дә яңгырап торды. Дини кардәшләребез арасында мөнәҗәтләр әйтүче, дини ширырьәр сөйләүче осталыклары да чагылды. Бигрәк тә Найлә ханым Адельшина, Дамирә ханым Абдуллина, Мәрьям апа Зәбирова һ.б. күңелләрне дулкынландырып, йөрәкләрне тынычландырып ләззәтләнүгә ирештерделәр.

Биредә ишеткән һәр хәдис файдалы һәм кирәкле иде. Халык аны чын фикерләп тыңлады һәм күңеленә сеңдерергә тырышты. Аннары бәйрәм, шушы шәкертләр тырышлыгында хәзерләнгән ризыклар, чәй өстәлләре артында дәвам итте.

**Майзә МАСИЕВА.**

01 информирует

# Уважаемые Старокулаткинцы!

Самые распространенные природные пожары – это травяные палы. В большинстве случаев причиной возгораний является человеческий фактор. Безответственное отношение поджигателей к имуществу и здоровью окружающих приводит к необратимым последствиям.

С установлением теплой и сухой погоды приобретает актуальность проблема стихийного сжигания сухой травы. Граждане сжигают мусор и прошлогоднюю траву на своих огородах и дворовых территориях, а дети поджигают траву у дорог и на пустырях. Весной прошлогодняя трава быстро высыхает на солнце и легко загорается от любой искры. Травяные палы быстро распространяются, особенно в ветреные дни. Горение стерни и сухой травы – процесс неуправляемый. Остановить хорошо разгоревшийся пожар бывает очень непросто. Нередко от травяных пожаров сгорают дома или даже целые поселения. Привычное многим сжигание травы оборачивается тем, что плодородный слой почвы будет восстанавливаться после такого пала минимум семь лет. Травяные палы вызывают очень сильное задымление. Во время горения стерни, мусора и других отходов, в атмосферу выделяется огромное количество опасных веществ, отравляющих окружающую среду. Травяные палы во многих случаях становятся причиной более катастрофичных пожаров – лесных и торфяных.

**Уважаемые жители района, чтобы в ваш дом не пришла беда, соблюдайте элементарные правила пожарной безопасности:**

- Не поджигайте траву и стерню.
- Не производите бесконтрольное сжигание мусора и разведение костров.
- Не разрешайте детям баловаться со спичками, не позволяйте им сжигать траву.
- Во избежание перехода огня с одного строения на другое, очистите от мусора и сухой травы территорию хозяйственных дворов.
- Не бросайте горящие спички и окурки.
- Не оставляйте на освещенном солнцем месте бутылки или осколки стекла.
- Не разжигайте костры в сухую и ветреную погоду, не оставляйте их непотушенными.

Если вы обнаружили начинающийся пожар, например, небольшой травяной пал, постарайтесь затушить его самостоятельно. Иногда достаточно просто затоптать пламя (правда, надо подождать и убедиться, что трава действительно не тлеет, иначе огонь может появиться вновь).

Если пожар достаточно сильный, и вы не можете потушить его своими силами, постарайтесь как можно быстрее оповестить о нем тех, кто должен этим заниматься. Позвоните в пожарную охрану (телефон 01, с мобильного 112, 101) и сообщите об обнаруженном очаге возгорания и как туда добраться.

**Доводим до Вашего сведения, что Приказом МЧС России №26 от 26.01.2016 утвержден Порядок использования открытого огня и разведения костров на землях сельскохозяйственного назначения, землях запаса и в частных домовладениях:**

1. Использование открытого огня должно осуществляться в специально оборудованных местах при выполнении следующих требований:

а) место использования открытого огня должно быть выполнено в виде котлована (ямы, рва) не менее чем 0,3 метра глубиной и не более 1 метра в диаметре или площадки с прочно установленной на ней металлической емкостью (например: бочка, бак, мангал) или емкостью, выполненной из иных негорючих материалов, исключающих возможность распространения пламени и выпадения сгораемых материалов за пределы очага горения, объёмом не более 1 куб. метра;

б) место использования открытого огня должно располагаться на расстоянии не менее 50 метров от ближайшего объекта (здания, сооружения, постройки, открытого склада, скирды), 100 метров - от хвойного леса или отдельно растущих хвойных деревьев и молодняка и 30 метров - от лиственного леса или отдельно растущих групп лиственных деревьев;

в) территория вокруг места использования открытого огня должна быть очищена в радиусе 10 метров от сухостойных деревьев, сухой травы, валежника, порубочных остатков, других горючих материалов и отделена противопожарной минерализованной полосой шириной не менее 0,4 метра;

г) лицо, использующее открытый огонь, должно быть обеспечено первичными средствами пожаротушения для локализации и ликвидации горения, а также мобильным средством связи для вызова подразделения пожарной охраны.

2. При использовании открытого огня в металлической емкости или емкости, выполненной из иных негорючих материалов, исключающей распространение пламени и выпадение сгораемых материалов за пределы очага горения, минимально допустимые расстояния, предусмотренные подпунктами «б» и «в» пункта 1 настоящего Порядка, могут быть уменьшены вдвое. При этом устройство противопожарной минерализованной полосы не требуется.

3. В целях своевременной локализации процесса горения емкость, предназначенная для сжигания мусора, должна использоваться с металлическим листом, размер которого должен позволять полностью закрыть указанную емкость сверху.

4. При использовании открытого огня и разведения костров для приготовления пищи в специальных несгораемых емкостях (например: мангалах, жаровнях) на садовых земельных участках, относящихся к землям сельскохозяйственного назначения, противопожарное расстояние от очага горения до зданий, сооружений и иных построек допускается уменьшать до 5 метров, а зону очистки вокруг емкости от горючих материалов - до 2 метров.

5. В случаях выполнения работ по уничтожению сухой травянистой растительности, стерни, пожнивных остатков и иных горючих отходов, организации массовых мероприятий с использованием открытого огня допускается увеличивать диаметр очага горения до 3 метров. При увеличении диаметра зоны очага горения должны быть выполнены требования пункта 1 настоящего Порядка. При этом на каждый очаг использования открытого огня должно быть задействовано не менее 2-х человек, обеспеченных первичными средствами пожаротушения и прошедших обучение мерам пожарной безопасности.

6. В процессе использования открытого огня запрещается: осуществлять сжигание горючих и легковоспламеняющихся жидкостей (кроме жидкостей, используемых для розжига), взрывоопасных веществ и материалов, а также изделий и иных материалов, выделяющих при горении токсичные и высокотоксичные вещества;

оставлять место очага горения без присмотра до полного прекращения горения (тления);

располагать легковоспламеняющиеся и горючие жидкости, а также горючие материалы вблизи очага горения.

7. После использования открытого огня место очага горения должно быть засыпано землей (песком) или залито водой до полного прекращения горения (тления).

**Будьте бдительны!**

**При возникновении любых чрезвычайных ситуаций звоните нам по телефону: 01, либо 112, 101 по сотовой связи.**

**А.Д. ШАМИОНОВ,**
**Заместитель начальника 30 ПЧ.**
**В.С. АЗИЗОВ,**
**Заместитель начальника ОНД по Павловскому, Радищевскому и Старокулаткинскому районам подполковник внутренней службы.**

# Для инвалидов по зрению

При Национальном Исламском Благотворительном фонде «Ярдэм» действует Лечебно-учебный реабилитационный центр для слепых и людей с остаточным зрением, который на регулярной основе проводит курсы. Центр расположен при одноименной мечети «Ярдэм», который был построен специально для незрячих с учетом всех их особенностей. Здание оборудовано лифтами с голосовым сообщением, поручнями, тактильной разметкой на полу, надписями у каждого кабинета по системе Брайля. Необходимо отметить, что все расходы берет на себя фонд, оплачивая проезд в оба конца, питание, проживание, общение и медицинскую помощь. Курсы проходят по обширной программе: обучение компьютерной грамотности, ориентировка на местности, уроки по домоводству и прикладному искусству, чтение и письмо по системе Луи Брайля. Также по рельефно-точечному тактильному шрифту обучают чтению Священного Корана. Для слабовидящих оснащен класс с оборудованием, увеличивающим текст до 36 раз. Цель фонда - помочь в социализации вновь ослепшим и помочь в саморазвитии остальным. Учитывая малоподвижный образ жизни, на курсах проводится элементарная реабилитация, которая включает консультацию офтальмолога, курс массажа, комплексное обследование здоровья в медицинском центре, ежедневную лечебно-оздоровительную гимнастику. Начинается новый набор на курсы, который будет проходить с 25 мая по 25 июня 2017г.

Мечеть "Ярдэм" приглашает незрячих и слабовидящих из общества слепых Старокулаткинского района на месячный курс реабилитации в лечебно - учебный реабилитационный центр для слепых в г. Казань. Телефоны для справок: 2-13-95 с 8 до 12 часов. Адрес: р.п. Старая Кулатка, здание администрации, кабинет 103, общество слепых.

# «Социальное мошенничество: как не стать жертвой»

Несмотря на неоднократные предупреждения сотрудников полиции о необходимости проявлять осторожность и бдительность, доверчивые граждане продолжают попадать в сети аферистов, расставаясь со своими сбережениями.

УМВД России по Ульяновской области напоминает, что мошенники представляют собой особую категорию правонарушителей. Если ранее с подобного рода преступлениями у граждан ассоциировались лишь лица цыганской национальности, то сейчас на этой ниве промышляет многочисленная плеяда контактных, симпатичных и порой даже обаятельных людей, имеющих завязать разговор и направить его в нужное русло.

Одним из распространенных видов мошенничества является социальное, жертвами которого в первую очередь становятся люди пожилого возраста.

Нередко обманщики входят доверие к пенсионерам под видом сотрудников социальных организаций, предлагают приобрести медицинские приборы по льготной цене, которые, как правило, продаются в ограниченном количестве и пенсионеры торопятся приобрести чудо – технику. Пожилые жители региона верят незнакомцам, потому что с ними говорят с использованием медицинских терминов, быстро, не давая тем самым времени осмыслить полученную информацию.

Излюбленным способом обмана пенсионеров является тема предстоящего обесценивания денег, в связи с которым мошенники предлагают гражданам обменять имеющиеся у них денежные средства.

Уважаемые граждане, будьте бдительны! Отдельно обращаемся к пенсионерам – не впускайте в дом посторонних людей, даже днем, даже, если они называют вас по имени и отчеству. Если нежданные визитеры представились сотрудниками почты, соцзащиты, пенсионного фонда и предлагают вам сомнительные операции с денежными средствами – не ленитесь и позвоните в соответствующую организацию за уточнением всех подробностей. Если вам показывают удостоверение, обязательно позвоните в организацию, которую этот человек представляет, и уточните, работает ли там такой сотрудник.

Не верьте рекламе чудодейственных препаратов и приборов, обеспечивающих быстрое исцеление от недугов.

**Т.Г. ГУРЬЯНОВА.**

**Информация об исполнении бюджета муниципального образования "Старокулаткинский район" по состоянию на 01. 04. 2017 г.**

| Наименование показателя | План | Кассовое исполнение |
|---|---|---|
| **Всего доходов** | **219917,1** | **46835,0** |
| в т.ч. | | |
| *- собственные доходы* | 18862,2 | 4572,7 |
| *-безвозмездные поступления* | 201054,9 | 42262,3 |
| **Всего расходов** | **219917,1** | **46288,6** |
| в т.ч. | | |
| *-общегосударственные вопросы* | 34877,6 | 7184,9 |
| *-национальная оборона* | 160,5 | 40,3 |
| *-национальная безопасность и правоохранительная деятельность* | 654,6 | 180,4 |
| *-национальная экономика* | 25064,1 | 1943,3 |
| *-жилищно-коммунальное хозяйство* | 6351,6 | 393,1 |
| *-образование* | 107176,9 | 25253,1 |
| *-культура, кинематография и средства массовой информации* | 14468,4 | 3550,8 |
| *-социальная политика* | 21266,1 | 5317,9 |
| *-физическая культура и спорт* | 100,0 | 38,5 |
| *-межбюджетные трансферты* | 9797,3 | 2386,5 |
| **Численность муниципальных служащих органов местного самоуправления, шт.ед.** | 29,0 | |
| **Расходы на оплату труда муниципальных служащих органов местного самоуправления, тыс.руб.** | 1896,6 | |
| **Численность работников муниципальных учреждений, чел.** | 667 | |
| **Расходы на оплату труда работников муниципальных учреждений, тыс.руб.** | 29341,4 | |

**Информация об исполнении бюджета муниципального образования "Старокулаткинское городское поселение" за 1 квартал 2017 год**

| Наименование показателя | План | Кассовое исполнение |
|---|---|---|
| **Всего доходов** | **13540,6** | **2833,8** |
| в т.ч. | | |
| - собственные доходы | 11365,7 | 2290,8 |
| -безвозмездные поступления | 2174,9 | 543,0 |
| **Всего расходов** | **13540,7** | **2579,3** |
| в т.ч. | | |
| -общегосударственные вопросы | 47,5 | |
| -национальная оборона | | |
| -национальная безопасность и правоохранительная деятельность | 63,0 | 50,4 |
| -национальная экономика | 4630 | 344 |
| -жилищно-коммунальное хозяйство | 6025 | 1549,4 |
| -культура, кинематография и средства массовой информации | 2775,2 | 635,5 |

Глава администрации И.А. Аблязов.

Патриотик тәрбия

# Герой кайта мәрмәр бюст булып



Шушы уңайдан ул көнне Кореновск шәһәреннән Герой - якташыбызның якын дусты Эдуард Анатольевич һәм аның хатыны Ольга Петровна Шегедалар килгәннәр иде. Алар иң беренче Иске Кулаткы икенче номерлы урта мәктәбендә булып укытучылар һәм укучылар белән якыннан торып очраштылар.

Бу күрешүдән соң Иске Кулаткы район культура йортында "Батырлык дәресе" оештырылды. Аны Иске Кулаткы район администрациясе Башлыгының вазифаларын вакытлыча башкаручы В. А. Деникаева һәм Иске Кулаткы икенче номерлы урта мәктәбенең Х сыйныф укучысы Эльвира Деникаева алып бардылар.

Озак та үтми сәхнә түрендә Кореновск шәһәренең 55 нче Кутузов орденына лаек булган вертолет полкы штабының урынбасары, Р. Хәбибуллинның якын дусты, майор Э. А. Шегеда урын алды. Ул якташыбызның исемен данлап аның батырлыгы турында сөйләде һәм мәктәп укучылары Ю. Разакованың, Э. Мавлютованың, Б. Бекеровның сорауларына җаваплар кайтарды.

Э. А. Шегеда үзенең чыгышында Кореновск шәһәренең өченче номерлы урта мәктәбе алдында Р. Хәбибуллинның бюсты куелуы турында һәм Иске Кулаткы районында да ике бюст алып килүләре турында белдерде. Ул шулай ук якын арада Улан-Удэ шәһәренең вертолет заводында Рәфгать Хәбибуллин исемен йөрткән зур хәрби вертолетның ясалуы турында да әйтте.

Бу очрашуда яисә "Хәрби батырлык" дәресендә мәктәп укучылары Р. Хәбибуллиның образын ачыклап язган сочинениеләренә дә бәя бирелде. Алар арасында Кирюшкино башлангыч мәктәбенең икенче класс укучысы Гүзәл Сафинаның, Иске Кулаткы икенче номерлы урта мәктәбе укучылары Юлия Зөлкәрнәеваның, Алсу Разакованың, Иске Кулаткы беренче номерлы урта мәктәбе укучысы Гөлназ Мамадалееваның сочинениеләре уңай дип бәяләнделәр һәм шуның өчен аларга олы бүләкләр тапшырылды.

Әлеге очрашуда район мәдәният бүлегенең һәвәскәр артистлары сәхнә түреннән тамашачыларга патриотик рухта җырлар да тәкъдим иттеләр.



Аннан соң Иске Кулаткы районының флаглар мәйданында Рәфгать Хәбибуллинның мемориаль тактасы алдына венок һәм чәчәкләр куелды.

Хәрби батырлык дәресләре узгач район балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбендә укучыларның хәрби парады булды. Бу парад белән Иске Кулаткы беренче номерлы урта мәктәбе укытучысы Рәис Рафаэлович Абдрәхимов командалык итте. Ул укучыларның хәрби парадка әзелекләре турында майор Э. А. Шегедага доклад ясады һәм укучылар аның каршыннан тантаналы марш белән уздылар.

**Рөстәм АРИФУЛЛИН.**
**Автор фотолары.**

# Авылының рухи терәге

Гажәеп киң күңелле кешеләр яши минем туган авылымда. Сүзем Кирюшкино авылының иң хөрмәтле кешесе, авылыбызның имамы Зөфәр Зөлкәрнәй улы Нарбиков турында.

Авылны авыл итеп бүген нәрсә яшәтә? Әлбәттә, халкының эшсөярлеге һәм булдыклылыгы, тәртибе һәм тәрбиялелеге. Менә шушы кадерле кыйммәтләр сагында торучы, аларны чык тамчысыдай халкы күңеленә иңдерүче чын имамнары – рухи таянычлары булган авыллар, чын мәгънәсендә, бәхетле. Кирюшкино авылыбыз да шул бәхетлеләр исәбендә. Чөнки аның олы җанлы имамы – Зөфәр абый Нарбиков бар.



Зөфәр абый 1937 елның 20 маенда Алма – Ата шәһәрендә әти-әнисенең бишенче балалары булып дөньяга килә. Ачлыктан һәм авырулардан соң 4 балаларын югалткан Нарбиковлар гаиләсе 1940 елда туган авылларына кайталар. Тик 1941 елда башланган сугыш, гаиләнең якты киләчәккә булган өметләрен юкка чыгара. Зөфәр абыйның әтисе Зөлкәрнәй Хәйруллович хатыны белән улын калдырып, сугышка китә. Тик туган җиренә әйләнеп кайтырга аңа насыйп булмый инде. 1943 елда Германия илендә әсирлеккә эләгә һәм һәлак була. 5 яшендә әнисе белән генә калган Зөфәр абыйга бик күп авырлыклар татырга туры килгән.

"5 сыйныфта укыганда ук әнием белән үгез җигеп, кырда эшләүчеләргә су ташый идек. Урманга йөреп кышкыга утынны да үзебез әзерли идек. Ничек кенә авыр булса да, әнием һәрвакыт чыдарга һәм сабыр булырга өйрәтте. Мәктәпне тәмамлагач, механизаторлар әзерли торган курсларны тәмамладым һәм авылыбызда механизатор булып хезмәт биографиямне башладым. Аннары токарь, юллар ремонтлаучы булып та эшләргә туры килде. Тулаем хезмәт стажым 45 елга тулды. Колхозда нинди эш бар, шунда эшли идек. Ул елларда авылыбыз халкы бердәм булып, санашмыйча эшләдек", - дип сөйли Зөфәр абый.

22 яшендә Зөфәр абый Яңа Терешка авылы кызы Мәрьям Рызвановна белән матур гаилә корып җибәрәләр. Мәрьям апа да сугыш елы баласы буларак, кечкенәдән үк авыр хезмәттә чыныгып үскән авыл баласы. Нарбиковларның гаиләсенә килен булып төшкәч, каенанасы белән уртак тел табып, 24 ел дәвамында татулыкта яшиләр. Авыраган әниләрен хөрмәтләп карыйлар һәм соңгы юлына озаталар. Дога мәҗлесләрен даими үткәреп, бүген дә мәрхүмәне җылы сүзләр белән генә искә алалар. Зөфәр абый белән Мәрьям апа авылда үрнәк гаилә булып 2 ул һәм 3 кыз тәрбияләп үстерделәр. Балалары да әти-әниләренең йөзләренә кызыллык китергәннәре юк. Һәммәсе дә матур гаиләләр корып, әти-әниләренә оныклар бүләк иттеләр. Нарбиковларның бүгенге көндә горурланырдай 17 онытклары һәм 11 оныкчалары үсеп килә.

"Балачактан мәхрүм булсак та, Аллаһы Тәгалә безгә дөньялыкта изге җирләргә хаҗ кылып кайтырга көч-куәт, саулык бирде. Изге җанлы район Башлыгы Э. Ә. Ганеевның ярдәме белән барлык изге урыннарда һәм хаҗ сәфәрендә булу бәхетенә ирештек. Бүгенге көндә улыбыз Кыям, кызыбыз Гүзәл һәм киявебез Дамир да хаҗ сәфәрен кылдылар. Аллага шөкер, барчабыз да Ислам динебезнең кануннарын үтәп яшәргә тырышабыз", - ди Зөфәр абый.

Зөфәр абыйның туган авылында имам вазифаларын башкаруына да 10 ел тулды. Гыйлемле, гадел, җаваплы имам менә шушы үтә нечкә вазифаны йөрәге кушканча, намус белән башкара. Яшьләргә никах уку, балага исем кушу, соңгы юлга озату кебек кеше гомерендәге мөһим чорларга бәйле дини йолаларны җиренә җиткереп үти, Ураза һәм Корбан бәйрәмнәренең тиешенчә һәм күркәм оештырылуына ирешә. Моңлы мәкаме, ягымлы тавышы белән тиешле Коръән аятьләрен укуыннан, эчтәлеген аңлатуыннан, мәгънәле вәгазеннән мәҗлестәгеләр бик канәгать кала, күңелләренә җиңеллек, рәхәтлек ала. Миңа калса, чын, заман таләп иткән имам нәкъ Зөфәр абый кебек: намуслы һәм җаваплы, гыйлемле һәм ихлас, сабыр һәм тыйнак булырга, һәркем белән уртак тел таба белергә, кешеләрне, яшәүне яратырга тиеш. Нинди генә хәлдә дә Зөфәр хәзрәт тавышын күтәрмәс, ә бәлки тыныч кына, кеше күңеленә хуш килерлек итеп яхшылап аңлатыр, кирәген төшендерер.

Менә шулай балалар тәрбияләп, авыл, мәчет тормышын хәстәрләп, еллар агымсудай аккан да аккан. Зөфәр Зөлкәрнәй улына да шушы көннәрдә 80 яшь тула. Олы юбилеегыз уңаеннан Сезгә корычтай нык сәламәтлек, тыныч тормыш, шатлык-сөенечләрнең зурысын, гомернең озынын, хәерлесен телибез. Алдагы көннәрегездә дә үзегезнең барлыгыгыз белән авылдашларыгызны, якыннарыгызны сөендереп яшәргә Ходай Тәгалә насыйп итсен.

**Гөлназ КУЗӘЕВА.**

# Хәрби җыр белән стройда йөрү конкурсында

Бөек Җиңүнең 72 еллыгын билгеләү кысаларында мәктәпләрдә хәрби җыр белән стройда йөрү смотр-конкурсы үтте. Бу ярышка һәр сыйныф җитәкчесе һәм укучылар бик җаваплы карадылар: форма, атлау тәртибе, җырны башкару осталыгы, речёвка, рапорт тапшырулар кат - кат кабатланды.



Биредә җиңүче командалар район этабында катнаштылар. Әлеге бәйге Иске Кулаткы балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбендә оештырылды. Таләпчән жюри әгъзалары конкурста катнашучыларның ничек киенүләренә, сафта тору дисциплинасына, бердәмлеккә, командирның гамәлләренә, аның командасын үтәүгә, җырлар башкаруга бәя бирделәр. Нәтиҗәдә өлкән группада Иске Кулаткы беренче номерлы урта мәктәбенең Х сыйныф укучылары җиңү яулады.

Урта звенода әлеге мәктәпнең кадетлар - VII сыйныф иң осталары булдылар. Ә инде башлангыч сыйныфлар арасында Иске Кулаткы икенче номерлы урта мәктәбенең IV сыйныф укучыларына тиңдәшләр булмады.

Призерларга район администрациясе Башлыгы исеменнән Почет грамоталары тапшырылды. Жюри әгъзалары балаларның ык әзерләнүен һәм аларны патриотик рухта тәрбияләүдә әлеге конкурсның әһәмияте зур булуын билгеләделәр.

# Файдалы экскурсиядә

"Тормыш куркынычсызлыгы нигезләре" исеме астында үткәрелгән Бөтенроссия ачык дәрес кысаларында Иске Кулаткы беренче номерлы урта мәктәбенең VI "А" һәм VI «Б» сыйныф укучылары класс җитәкчеләре Э. А. Кузәева һәм Д. Р. Байбикова белән Иске Кулаткы эшчеләр бистәсендә урнашкан 30 санлы янгын сүндерү частендә булдылар.

Янгын күзәтү службасы начальнигы В.С. Азизов, караул начальнигы Р. Х. Шәрипов, бүлек командиры Р. Р. Хайров һәм янгын сүндерүче Д. А. Салихов балаларга янгын белән аяусыз көрәшүчеләрнең батыр хезмәтләре, аларның эш киемнәре, янгын сүндерү вакытында нинди инвентарьлар кулланулары турында сөйләделәр. Хәзер мондагы техника елдан - ел камилләшә бара, янгын сүндерү машиналары заманча җиһазлар белән коралланган.



Хезмәткәрләр дә үзләренең һөнәри осталыкларын даими камилләштереп тора. Укучыларга учакны яки хәтта кухняда янып киткән сөлгене һәркем сүндерә алуы турында сөйләделәр, әмма тулы масштаблы янгын турында сүз барганда, ут стихиясе белән алышка батыр һөнәрманнар керешә. Коткару хезмәтендә кешеләрне коткарырга һәм якларга сәләтле, һәр көнне авырлыкның күзенә кыю рәвештә карый алган фидакарьләр генә эшли ала. Балаларга бигрәк тә бу служба ошады. Алар әледән - әле өлкән абыйларына янгыннан саклау хезмәтенең тарихы һәм һөнәри эшчәнлек турында сорауларны яудырып кына тордылар. Ачык кызыл төстәге техника һәм сирена тавышы укучыларны тәэсирләндерде. Балаларга КамАЗ кабинасына утырырга һәм барысын да үз куллары белән тотып карарга рөхсәт ителде. Иң мөһиме – укучыларда йорт һәм җәмәгать милке иминлеге өчен җаваплылык хисе барлыкка килде.

**Э. А. КУЗӘЕВА,**
**укытучы – социаль педагог.**

# ТӘБРИКЛӘҮЛӘР!

**Кирюшкино авылында гомер кичерүче Зөфәр Зөлкәрнәевич НАРБИКОВ 20 май көнне 80 яшьлек олы юбилееннан каршы ала.**

**Кадерле тормыш иптәшем, хөрмәтле әтиебез, яраткан бабакаебыз!**

Сине ихлас күңелдән юбилеең белән тәбрик итәбез. Сиңа аяз күк йөзе, корычтай нык сәламәтлек, кояштай озын гомер, чиксез шатлыклар телибез. Сабыр холыклы, мәрхәмәтле, ярдәмчел, кадерледән кадерле син. Киләчәктә дә киң күңелле, ачык йөзле, олы йөрәкле булып кал. Ходай насыйп итеп сиңа алдагы көннәреңдә дә сәламәтлек белән гомер итәргә, безнең шатлыкларга сөенеп яшәргә язсын иде.



*Һәрчак шулай тәрәзәдән,*
*Балкып янса иде утыгыз.*
*Озак еллар безне каршы алса иде,*
*Сез яшәгән туган йортыбыз.*

**Иң изге теләкләр белән тормыш иптәшең Мәрьям Рызвановна, уларның Кыям - Венера, Камил - Эльвира, кызларың Зәлифә - Абдулсамәт, Асия - Тәүфыйк, Гүзәлия – Дамир, 17 оныгың, 11 оныкчаң, кода – кодагыйларың һәм барлык туганнарың.**

Кирюшкино - Норильск – Ногинск – Казан – Ульяновск – Тереньга – Сызран – Радищево – Иске Зеленай – Яңа Терешка.

**Иске Мостяк авылында туып үскән хәзер Мосеевкада гомер итүче Зәкия Мөбин кызы ИБРАЕВАГА 20 майда 75 яшь тула.**

**Кадерле тормыш иптәшем, яраткан әниебез, сөекле әбекәебез!**

Без синең чын күңелдән юбилейлы туган көнең белән котлыйбыз. Аллаһы Тәгалә сиңа исәнлек-саулык, озын гомер, җан тынычлыгы, бәрәкәтле тормыш, иман байлыгы, әтиебез белән тигезлектә яшәвегезне телибез. Киләчәктә дә без бала-оныкларыңның рәхәтен күреп, шатлык-куанычта, барлыкта-муллыкта яшәргә язсын сиңа.



*Рәхмәт, әнкәй, барысы өчен дә,*
*Без бәхетле синең янында.*
*Син зур терәк безгә һәрвакытта,*
*Тормыш ямьле тик син барында.*
*Кирәк түгел алтын кәмеше дә,*
*Читтә торсын барлык байлыклар.*
*Ишек ачып өйгә кайтып кергәч,*
*Ярый әле каршы алу өчен әни бар!*

**Иң изге теләкләр юллап, тормыш иптәшең Рәис Аббәсович, улың Марс, кызларың Нурия, Руфия, Рәйсә, киленең Эльмира, кияүләрең Шәүкәт, Дамир, Илмир, оныкларың Эльмира-Рафаэль, Альбина-Ренат, Марсель, Айрат, Илнур, Динара, Эльнара, оныкчаларың Регина, Ильяс, апаң Зәйтүнә, кода-кодагыйларың һәм барча туганнарың.**

Мосеевка – Иске Мостяк – Евлейка – Тольятти – Ульяновск.

**Спорт - Спорт - Спорт**

# Шахматчыларыбызның уңышлары



Соңгы вакытта Ульяновск өлкәсе Хөкүмәте регионда спорны үстерүгә зур игътибар бирә. Безнең Иске Кулаткы районы командалары да тәрле өлкә ярышларында еш рак катнаша башладылар. 13 май көнне Ульяновск шәһәрендә укучыларның шахмат буенча спартакиадасы үтте. Биредә 17 команда катнашты.

Безнең районның даның Иске Атлаш урта мәктәбе укучылары: Илнур Сәйфетдинов, Алина Габитова, Илдар Рафиков һәм Алина Сәйфетдинова яклады. Ярышлар командалы, швейцар системасы белән 7 турда үтте. Һәрбер партиягә 10 минут вакыт бирелде. Командабыз җиңүгә омтылып, шахмат уйнауда осталыкларын күрсәтте һәм өченче урынны яулады. Шәхси беренчелектә Алина Габитова өченче урынга лаеклы булды.

Команда беренчелегендәге призерлар өлкә физик культура һәм спорт Министрлыгының Почет Грамоталары һәм кубоклары, ә инде шәхси беренчелектә җиңүчеләр медальләр белән бүләкләнделәр.

Шулай ук әлеге спартакиадада безнең мәктәптән III – IV сыйныф укучылары: Шамил Габитов, Динар Насыров, Айсылу Сәйфетдинова һәм Эльза Хамзина икенче команда составына керделәр. Әлеге команда бишенче урынга чыкты. Яңа шахматчылар буыны вәкилләренә киләчәктә зур уңышларга ирешүләрен теләп калабыз.

Форсаттан файдаланып, район администрациясенә ярышларга баруны оештыруда ярдәм күрсәткәне өчен рәхмәт белдерәбез.

**Газинур ЮРТАЕВ,**
**"Ак ладья" шахмат клубы җитәкчесе.**

**12 май - Халыкара шәфкать туташлары көне**

# Табиб кулында - кеше гомере

Тормыштагы авырлыклар көтмәгәндә-уйламаганда туа шул. Авыру да кемнең-кем икәнен карап тормый: олымы ул кеше, әллә яшь баламы, чир өчен моның мөһим түгел. Чак кына авырасак та: "Сәламәтлегемне кайтар,"- дип, Ходай Тәгаләгә ялварабыз һәм терелү өмет итәбез. Аллаһы Тәгалә безгә ярдәмгә ак халатлы кешеләрне җибәрә. Аларның күңеленә кешеләрне ярату һәм мәрхәмәтлелек иңдерә. Соңгы елларда безнең гаиләбезгә дә мәрхәмәтсез авыруның зур сынавы белән очрашырга туры килде. Менә бу юлы да өлкә больницасыннан дәвалану курсын үтеп кайтуыма карамастан, кинәттән хәлем начарайды һәм ашыгыч ярдәм машинасын чакырттык. Тәҗрибәле фельдшерыбыз Суфия Җиһаншовна Мамадалеева мине тиз арада больницага җиткерде. Дежурда торучы табиб Галия Шәүкәтовна Мамадалеева тиешле ярдәмне күрсәтте һәм мине терапия бүлегенә урнаштырды. Якшәмбе көн булуга карамастан, тиз арада хирург Сергей Васильевич Тюхматьев, рентгенка төшерүче шәфкать туташы Наҗия Исәнова, лаборантка Гүзәл Дәүләтшовна тиешле анализларны ясадылар. Терапия бүлегенең өлкән шәфкать туташлары Гөлсинә Курамшина, Гөлсинә Сәләева, шәфкать туташлары Галия Исмаилова, Илмира Хамзина, Гөлшат Мохамедова, Гөлсем Хакимова, санитаркалар Фәридә белән Гөлнара, Рәхилә Алтынбаева үз эшләренең осталары буларак, авыруларга карата һәрвакыт игътибарлы, тиешле процедураларны төгәл һәм вакытында башкаралар. Бу бүлектәге чисталыкка да таң калырлык. Табиблар, шәфкать туташлары, санитаркалар, пешекчеләрнең дә миңа күрсәткән кадер – хөрмәтләре үзләренә әйләнеп кайтсын иде. Ходай рәхмәте белән бик яхшы табиблар кулына эләктем. Аерым рәхмәт сүзләремне яшь табибыз Регина Рафаэлевна Азизова адресына җиткерәсем килә. Регина Рафаэлевна яшь кенә булуына карамастан, үз эшен яратып башкаручы, һәрдаим авыруларга ярдәм итәргә ашкынган табиб. Ул үз һөнәренең ни дәрәҗәдә җаваплы булганлыгын аңлап эшли. Авыруларга карата сабыр, ачык йөзле булуы мине сокландырды. Көнне-төнне белми сәламәтлекләре какшаган авырулар янында булу, аларга ярдәм күрсәтү зур сабырлык сорый торган эш. Регина Рафаэлевна көн дә палатага кереп авыруларның хәлен белеше, әз генә борчылып торганны күрсә, үз туганыдай якын итеп кайгырта, төпле киңәшләрен бирә. Мине дә ул чын мәгънәсендә "Үлем тырнагыннан" коткарып калды. Ульяновск шәһәренең өлкә больницасында дәвалаучы табибым Маргарита Сергеевна Трифоновага да рәхмәтем иксез – чиксез. Регина Рафаэлевна өлкә табиблары белән элемтәгә керде, аларның киңәшләрен төгәл башкарып, мине аякка бастырды. Менә шулай саулыгыбызны югалткач кына табиблар кулында – кеше гомере икәнлеген яхшы аңлыйбыз. Халык ихтирамын һәм ышанычын яулау өчен безнең табибларбыз бөтен белемнәрен, һөнәри осталыкларын, авыруга карата җылы мөнәсәбәтләрен кызганмыйча эшлиләр. Алар кебек табиблар, шәфкать туташлары күбрәк булса, халыкның медицинага булган тискәре карашы да үзгәрер иде, мөгаен.

**Олы ихтирам белән**
**Сумия Сөләйманова.**
**Иске Кулаткы.**

# Тыныч тормыш өчен без аларга рәхмәтле

Бөек Җиңү көнен билгеләү уңаеннан мәктәпләрдә, балалар бакчаларында, китапханәләрдә, клубларда Бөек Ватан сугышы ветераннары, тыл хезмәтчәннәре, сугыш елы балалары белән очрашулар оештырылды. Шуларның берсе "Гөлчәчәк" балалар бакчасында да үтте. Ленинград блокадасында катнашучы Д.А. Алтынбаев, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар - Ш.Р. Арифуллин, Р.З. Тимербулатов, төрле елларда бирелә эшләп, ялга чыккан пенсионерлар, тыл хезмәтчәннәре, сугыш елы балалары - Т.М. Богданова, Р.Н. Кузахметова, М.И. Абәйдуллина, О.А. Кузьмина, Б.Я. Дивеева, нәниләрнең әбиләре, сугыш елы балалары - Х.Ш. Алькаева, Ә.Җ. Аюпова, район пенсионерлар Союзы рәисе Р.Я. Мусина һәм район мәгариф идарәсе начальнигы Ф.З. Зайнетдинова – бәйрәмнең олы кунаклары иде.



Балалар бакчасы мөдире Л.Ф. Богданова барлык авырлыкларны үз җилкәләрендә татыган, олы тормыш юлы үткән хөрмәтле ветераннарны Җиңү көне белән ихластан тәбрикләп, рәхмәтләр белдерде.

Балалар кунаклар хөрмәтенә хәрби җырлар, шигырьләр, биюләр башкардылар. Бөек Ватан сугышы темасы бүгенге балаларның күңелен дә тетрәндерә шул. Балаларның чыгышлары беркемне дә битараф калдырмады. Ул елларның кайгы-хәсрәтен үз җилкәләрендә татыган буын вәкилләре күз яшьләрен тыя алмадылар. Һәр чыгыш кайнар алкышларга күмелде.

Бәйрәм ахырында нәниләр кунакларга үз куллары белән ясалган бүләкләрне тапшырдылар. Район пенсионерлар Союзы рәисе Р.Я. Мусина барлык кунаклар исеменнән бакча коллективына олы рәхмәтләр әйтте.



Чараны оешкан төстә үткәрүдә тәрбиячеләр Ә.Х. Ханбикова, З.А. Юмангулова һәм музыкаль җитәкче Г.Д. Хабиева зур тырышлык куйдылар. Сугыш темасына зур игътибар биргән тәрбиячеләр олы рәхмәткә лаеклылар. Балалар тыныч тормышта яшәүләре өчен кемгә бурычлы булуларын белергә, оныт маска тиешләр. Мондый чара балаларда Ватанга мәхәббәт, ветераннарга карата ихтирам, патриотизм хисләре тәрбияләнәләр.

Бу тынычлыкны яулап алып биргән ветераннарга, сугыш чоры балаларына, тыл ветераннарына безнең рәхмәтебез чиксез. Сезнең батыр хезмәтегезне нич кайчан онытмабыз. Сезгә лаеклы алмаш булырбыз.

**Әлфия ЯФАРОВА.**

Сәламәтлек

## 21 май - СПИДтан үлүчеләрне Халыкара искә алу көне



21 майда СПИДтан үлүчеләрне Халыкара искә алу көне уңаеннан бөтен дөньяда шәмнәр кабызылачак. Әлеге традиция 1983 елда башланып, дөньяның 100 илендә ел саен билгеләнеп үтелә. Дөньяда ВИЧ белән зарарланган 75 миллион кеше яши, ә Россиядә андыйларның саны –1000000 кеше. Дөньяда әлеге чирне һәр 6 секундта бер кеше эләктерә. XX гасыр чире дип тә аталган СПИД елдан-ел күбрәк кешегә йога бара. Әлегә дәвасы табылмаган бу авыру кешегә гадәттә женси юлдан һәм, йогышлы энәләр кулланып, кан аша килеп эләгә.

ВИЧ-инфекцияле пациентларга килгәндә, бүген алар дәүләттән бушлай кыйммәтле медицина ярдәме алуга хокуклы. Бу махсус дәвалау чараларын куллану авыру кешенең канында саклаучы

Т-лимфоцитларның кимү процессын һәм чирнең клиник билгеләренең үсеше башлануын тоткарларга мөмкин. Әйе, сүз ВИЧ-инфекцияне тулысынча дәвалау хакында бармый, ләкин без ышанабыз: киләчәктә ВИЧ-инфекция белән ныклы көрәшергә мөмкинлек биргән препаратлар һичшиксез уйлап табылыр!

Әлеге көндә халыкка ВИЧ-инфекция турында аңлату уңаеннан зур эш алып барыла: матбугат чаралары, конференцияләр, ачык ишекләр көне, буклетлар тарату һ.б бу уңайдан әһәмиятле роль уйный. Бу бик тә мөһим эш һәм дөньяда инфекция эләктерүчеләр саны арта баруга карамастан, аны дәвам итү һәм яхшырта бару мөһим.

Шунысын да онытырга ярамый: медицина хезмәткәрләре һәм энтузиастлар тырышлыгы белән генә проблеманы хәл итеп бетерү мөмкин түгел һәм бернинди чара да бер эшкә дә 100 процент гарантия бирә алмый. Әлеге проблеманы чишүдә күп нәрсә кешенең үзеннән, аның үз гомеренә һәм сәламәтлегенә, башкаларга булган мөнәсәбәтеннән тора.

Яшәү рәвешенә караш һәрвакыт кешенең үз компетенциясендә, аны кечләп берни эшләтеп тә, бернәрсәне кечләп тагып та булмый. Табибның изге бурычы – үз эшен намуслы башкару: аңлату, лекцияләр уку, мәсьәләнең актуальлеген тормыш мисалларында күрсәтү, мәгълүмат бирү һ.б. Әгәр дә башкаларга килеп кагылган мондый зур бәла беребезне дә битараф калдырмаса, киләчәктә хәлләрнең уңай якка үзгәрәчәгенә иманым камил. Шуны онытырга ярамый, сәламәтлегебез – үз кулларыбызда! Үзегезне саклагыз һәм сәламәт булыгыз, хөрмәтле газета укучылар!

**Ф. З. БАХТИЯРОВА,**
**Иске Кулаткы район больницасында табиб-инфекционист.**

## Равил Фәйзуллин иҗатыннан



Татарстан республикасы Иске Кулаткы районының дуслык җепләре елдан ел ныгый һәм аралар да якынлаша дип әйтсәк, һич ялгыш булмас. Моның турында искекулаткылыларның Казан шәһәрендә булып, төрле форумнарда катнашулары, Казан шәһәреннән олы кунакларның Иске Кулаткыда булулары ачыктан-ачык дәлилилләр.

Быел 21-22 апрель көннәрендә Иске Кулаткы районында "Татар телен, милли мәдәниятне һәм гореф-гадәтләрне саклауда татар матбугатының роле" дип исемләнгән I татар милли матбугаты региоара фестивaленең узуы - югарыда әйтеп үткәннәрне тагын бер кат исбат итте. Бу чарда Г. Тукай премиясе лауреаты, Татарстанның халык шагыйре, "ТАТМЕДИА" АҖ генерал директоры киңәшчесе Равил Фәйзуллин олы кунак буларак катнашты. Шушы уңайдан без күренекле шагыйрь турында "Кумәк көч" район газетасының укучыларын якыннан таныштырырга һәм аның кайбер шигырьләрен аларның игътибарына тәкъдим итәргә булдык.

Равил Фәйзуллин — күренекле татар шагыйре. Ул 1940 елның 4 апрелендә Балык Бистәсе районының Балтач (Юлсубино) авылында туган. Котлы Бәкештә урта мәктәпне, 1965 елда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый. Армиядә хезмәт итеп кайткач, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты каршындагы аспирантурада укый. 1968-1972 елларда Татарстан язучылар берлегенең җаваплы секретаре була. 1989 елдан —"Казан утлары" журналының баш мөхәррире. 1996 елдан - Татар ПЕН-үзәге әгъзасы.

Шагыйрь урта мәктәптә укыганда яза башлый. Шигърият мәйданына "Казан утлары"нда басылган "Нюанслар иле" дигән шигъри циклы белән чыга. Шуннан соң аның "Рәсем ясыйм", "Аҗаган", "Монологлар һәм диалоглар", "Мәрмәр", "Гадиләргә гимн", "Наз", "Шигырьләр һәм поэмалар", "Кошлар юлы", "Якты моң", "Җырларда ил гаме" һ.б. күп китаплары, 5 томлык сайланма әсәрләре дөнья күрде. "Саз", "Суровая нежность", "Миг возвращения", "Мой звёздный час", "Полнолуние", "Короткие стихи" һ.б. китаплары рус телендә басылып чыкты.

22 апрельдә Равил Фәйзуллин "Кумәк көч" район газетасының журналистлары белән дә якыннан торып очрашты. Ул журналистларны үзенең тормыш юлы иҗаты, белән якыннан таныштырды.

**Рөстәм АРИФУЛЛИН.**

**Түбәндә без укучылар игътибарына күренекле шагыйрь - Равил Фәйзуллинның соңгы елларда иҗат иткән шигырьләрен тәкъдим итәбез.**

### Элек һәм хәзер

*Укучылар күп иде элек,*
*язучы сирәк иде.*
*Әсәр — рухи азык булып,*
*гавамга кирәк иде.*

*Хәзер укып вакланмыйлар,*
*һәммәсе «иҗат» итә!..*
*Китап башын*
*«китап» ашый*
*торган заманга җиттек.*

*Яшьләрдә — экран-китап.*
*Кызык та ул, яңа да.*
*...Кәгазь-китап охшап*
*калды*
*рәнҗетелгән анага.*

### Һәммәсе якыннар...

*Яшәлгән гомерләр,*
*язылган китаплар,*
*күрелгән шәһәрләр,*
*яраткан хатыннар —*
*һәммәсе якыннар!*

*Кырдагы игеннәр,*
*иртәнге ак карлар,*
*судагы дулкыннар,*
*уттагы ялкыннар —*
*һәммәсе якыннар!*

*Ай-кояш, йолдызлар,*
*тургайлар, былбыллар,*
*дус-ишләр, көндәшләр,*
*җырчылар, акыннар —*
*һәммәсе якыннар!*

*...Үзем генә үз-үземә*
*чит-ят кебек карап*
*торам.*

### Саталар...

*Саталар һәм сатылалар...*
*Бар дөньясы сатуда!*
*Аерма шул: сату сүзен*
*кем ничек аңлатуда.*

*Саталар грам-мыскаллап,*
*саталар илләтә дә!*
*Кемнәрдер ялшерен сата,*
*кемнәрдер — күрәләтә.*

*Саталар тәнен-гыйффәтен,саталар*
*урын-постын...*
*Сатасыңмы, сатыласыңмы*
*— син ни статуста, дустым?*

*... Һәммә кеше андый түгел*
*уеңда, дисең, хата.*
*Ышанмыйсың? Әнә чатта*
*кемдер гайбәтең сата.*

Мәктәп тормышы

## Батырлык дәресләре



Авылда яшәүче ветераннар белән мәктәбебез һәрвакыт тыгыз элемтәдә тора. Өйләренә барып, хәлләрен белү, бала вакытлары, зур кыенлыкларны кичеп үткән яшьлекләре турында әңгәмә кору, мәктәптә, клубта оештырыла торган чараларга чакыру – матур традициягә әверелде. Җиңүнең 72 еллыгын билгеләү кысаларында Иске Атлаш урта мәктәбендә I-IV сыйныфлар катнашында "Сугыш елы балалары" баш астында, ә инде V-IX һәм XI сыйныфлар өчен "Хәтер исән" исемле Батырлык дәресләре үтте. Әлеге чарага шушы авылга бар гомерләрен багышлаган, намуслы хезмәтләре белән үрнәк булган, акыллы, сабыр холыклы сугыш чоры балалары Ф.Я. Юртаев һәм Ф.М. Сыраҗетдинова чакырылды. Алар башлангыч сыйныфлар укучыларына яшьлектәге авыр тормышлары турында мавыктыргыч итеп сөйләделәр. Балалар кунакларны җылы кабул итеп, сөйләгәннәрен йотлыгып тыңладылар, үзләренә әйтелгән теләкләргә бик шатландылар. Бу очрашу укучылар өчен бик файдалы булды: туган якны яратырга, аңа тугры булырга, өлкәннәрне хөрмәтләргә кирәклеген алар тагын бер кат исләренә төшерде.

Урта һәм югары сыйныф укучылары Ленинград блокадасын үз күзе белән күрүче Н.И. Яфарова һәм сугыш елы баласы Х.М.Якупова белән очраштылар. Әлеге чараны IX сыйныф укучылары класс җитәкчеләре Г.К. Мөслимова ярдәмендә әзерләделәр. Балаларның нинди хисләр кичергәннәрен аларның күзләренә карап белеп була иде. Кунакларның сөйләгәннәрен игътибар белән тыңладылар алар. Әлеге апалар үзләренең генә түгел, ә шул заманда һәр авыл хатын-кызының башыннан үткән хәлен сөйләде. Ә бит әлеге вакыйгалар барчабызның да әбиләре һәм бабалары башыннан үткән. Балалар кунакларга сугыш турында әдәби-музыкаль композиция күрсәттеләр. Кунаклар әлеге чаралардан бик канәгать булдылар һәм мәктәп коллективына, укучыларга рәхмәтләрен белдерделәр.

Без үзебезнең сугыш чоры балалары белән горурланабыз, безгә киләчәктә дә изге теләкләр теләп, киңәшләр бирүләрен котәбез. Үз чиратыбызда, аларга озын гомер, исәнлек-саулык, тыныч илдә безнең уңышларыбызга куанып,кадерле әби-бабайлар булып яшәүләрен телибез.

**Наҗия ЧАМКАЕВА,**
**Иске Атлаш урта мәктәбенең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары.**

Дин, әхлак һәм вөҗдан иреге

## Тиздән Рамазан ае башлана

Дини календарьга күз салсак, быел - Яңа 2017 елда 27 майда Ураза башланачак. 25 июньдә Ураза гаетен билгеләп үтәчәкбез. 1 сентябрьдә Корбан гаете узачак.

Бөтен галәмнәргә рәхмәт, мәрхәмәт буларак җибәрелгән сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам үзенең бер хәдисендә болай дип әйткән: "Бер адәм рамазан аен шатланып каршы алса һәм рамазан аеның үтеп китүенә күңеле белән яхшы айлар үтте дип кайгырса, ул адәмгә мәңгелек сәгадәт, рәхәт йорты булган җәннәт важиб (тиешле) булыр". Икенче хәдис-шәрифтә әйтелгән: "Әгәр кешеләр рамазан аеның бөтен хасиятләрен, савапларын белсәләр, бөтен ел әйләнәсе рамазан ае булуны теләрләр иде" (имам Табарани, Бәйһәкый).

Рамазан — барлык гөнаһлардан пакьләнү, күңелләрне сафландыру, күркәм сыйфатлар белән бизәкләү ае. Рамазан фазыйләтенә багышланган бер хәдистә Расүлаллаһ галәйһиссәлам: "Өммәтем гади айда кылган бер яхшы гамәл өчен бер савап ала, әмма рамазанда исә Аллаһ бер яхшы гамәл өчен җиде йөзгә хәтле һәм аннан да күбрәк әҗер бирә. Фарыз гыйбадәтләренең берсе өчен башка айларда кылган җитмеш фарызның савабын, нәфелләре өчен исә башка айларда кылган фарызның савабын.

Уразаның мәгънәсе нәрсәдән гыйбарәт соң? Ураза сүзе "тыелу" дигәнне аңлата. Ураза тоткан кеше таң атканнан алып кояш баеганга кадәр ашау-эчүдән, женси мөнәсәбәтләрдән тоелып торырга тиеш. Әмма ураза камил булсын өчен без шулай ук ялган, гайбәт, начар сүзләр кебек кимчелекләрдән үзебезне сакларга тиешбез. Бу турыда сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам: "Кем уразалы була торып та ялган-гайбәттән тукталмый икән, аның ач йөрүеннән бернинди файда юк", — дигән (Ибне Мәҗә), ягъни үзен мөселман дип таныган кеше уразаны сәламәтлеге өчен яисә ябыгыр өчен түгел, ә рухый яктан камилләшер өчен тотарга тиеш. Без бу айда гүзәл холыкка, гүзәл әхлакка омтылырга тиешбез. Аллаһы Тәгалә Үзенең Китабында: "Яхшылык эшләргә ашыгыгыз, тәүбә кылырга ашыгыгыз, җәннәткә ашыгучылардан булырсыз. Ул җәннәтнең киңлеге җир һәм күкләр кадәрдер. Ул җәннәтләр тәкъвалылар өчен әзерләнде", — дигән ("Әл-Гыймран" сүрәсе, 133 нче аять). Шушы ук сүрәнең 134 нче аятендә Аллаһ Раббыбыз болай ди: "Ачуыгызны эчкә алыгыз, дошманнарыгызны гафу итегез, әлбәттә, Аллаһы Тәгалә игелек кылганнарны сөядер ". Менә без шушы айда яхшылык эшләргә ашыгырга тиешбез. Үз калебләребезне чистартырга, күркәм сүзләр сөйләргә тиешбез, гайбәткә кермәскә, кешене гаепләмәскә, ялганламаска тырышу лазем.

Хәләл ризыклардан, эчемлекләрдән тыелып, телләребезне гайбәттән саклап, күңелләребезгә пакь уйлар салып йөрсәк, бәлки Аллаһның рәхмәте булып, ел буе күңел сафлыгына ирешербез. Рәсүл Әкрам галәйһиссәлам әйткән: "Кем бу айда уразаның фарызлыгына ышанган һәм Аллаһ ризалыгын теләгән хәлдә ураза тотса, аның гөнаһлары кичерелер". (Бохари, Мөслим). Аллаһы Тәгалә кодси хәдисендә: "Ураза — Минем өчен хас гыйбадәттер. Аның әҗерен Үзем бирермен ", — дигән (Бохари, Мөслим). Намаз, зәкят һәм хаҗ гыйбадәтләре дә Аллаһ өчендер, ләкин уразаның үзенчәлеге — Аллаһ белән мөэминнен арасында сер булуында, шуның өчен аның әҗере дә олы. Ни өчен уразаны Аллаһы Тәгалә белән мөэмин арасындагы яшерен гыйбадәт дибез соң? Намаз укысак, зәкят бирсәк, хаҗга барсак, моннан адәмнәр хәбәрдар була, әмма ураза тотканыбызны фәкать үзебез һәм Аллаһы Тәгалә генә белә."Бәкара" сүрәсенең 183 нче аятендә: "Әй иман китергән кешеләр, сездән алдагы кавемнәргә фарыз булган кебек, сезгә дә ураза фарыз булды, уразаларыгызны тотыгыз, шаять тәкъва булырсыз ", — дип, вәгъдә биргән Аллаһның шушы рәхмәтеннән файдаланырга кирәк. Аллаһы Тәгалә хәерле сәламәтлекләр биреп, рамазан айларыбызны да. үзенә муафыйк булганча, изгелектә үткәрүләребезне насыйп итсә иде, чөнки акылыбызның зәкяте намаз булса, сәламәтлегебезнең зәкяте — ураза. Сәламәт булмаган, авыру кешегә ураза фарыз түгел. Сәламәт килеш изге айны каршы алганбыз икән, Аллаһ Раббыбыз аны изге гамәл-гыйбадәтләр белән үткәрүебезне насыйп итсә иде.

БЕРГӘЛӘП УКЫЙБЫЗ

# САГЫНЫРСЫҢ МИН БУЛМАМ

*Повесть*

**Зифа Кадырова**



Нинди сөенеч – Сөмбелнең дәү әнисе кунакка килгән! Ул күрше авылда кече улы, килене белән яши, җай булганда, Сөмбелләргә дә килгәли. Кызыкай аның белән эч серләрен сөйләшергә ярата, чөнки әбисе кызыксынып тыңлый белә, җитмәсә, беркайчан да ачуланмый. Бүген дә Сөмбелнең сөйләр сүзләре бик күп җыелган иде. Ул әбисен кочаклап алды.

- Дәү әни, дәү әни, мин шундый чибәр егет белән таныштым. Аны күрсәң иде: үзе озын буйлы, күк күзле, коңгырт чәчле. Шундый чибәр, бер дә безнең авыл егетләренә охшамаган, - дип бармакларын бөкләп санап китте. - Ә елмайса, елмайсамы - башларым әйләнеп китә, әбием!

- Әллә урысмы?

- Юк, ул татар. Ахун егете.

- Әй балам, юкка куанасың, минем белүемчә, Ахуннықылар элек-электән читтән кыз алмаган, читкә кыз бирмәгән.

- Дәү әни, син кайсы заманны сөйлисең?

- Гомер буе шулай булган. Алар бит үзләренә бер төрле халык. Элек-электән бай булганнар, үз авыллары эчендә генә алыш-биреш иткәннәр. Туйларны да бик зурлап үткәрәләр, үз йолалары бар. Элек шулай иде.

- И дәү әни, хәзер бит җитмешенче еллар ахыры, кем-кемне ярата, шуны ала. Тагын сөйлә әле алар турында.

Кызының әбисе белән сөйләшүен тыңлап торган әнисе дә сүзгә кушылды:

-Сөмбел, балам, гыйшык-мыйшык уйнап башыңны әйләндермә, укырга кирәсең бар. Шундый яхшы аттестат белән укымыйча, кияүгә чыгып, һөнәрсез калыргамы? Егетләр бетмәс ул, итәк-чабуыңны җыеп йөр, киләсе елга укырга керергә әзерлән.

Тик яшь кыз чибәр Ахун егете Булаттан башка берни хакында да уйлый алмый иде инде...

Алар бер тулай торакта торалар. Бу йорт Учалының иң матур урынында, урман янындагы тау битенә урнашкан. Сөмбел белән Булат шушы тулай торакта, кызыл почмакта кичке танцыда таныштылар.

...Бер читтә басып торучы озын буйлы егетне күреп, Сөмбел өнсез калды. Кичәне алып баручы:

- Ә хәзер ак танец, кызлар егетләрне чакыра, - дигәч, Сөмбел, бу чибәр егетне берәрсе алып киткәнче дип, аның каршысына йөгереп килеп тә басты. Аның янында үзенең бөтенләй кыска буйлы булуын аңлап, беразга аптырап калды. Егетнең күзләренә карагач, аяклары йөрмәс булды: мондый матур зәңгәр күзләрне аның беркайчан да күргәне юк иде. Ә ул, кызга карап, ап-ак тешләрен ялтыратып елмайды да, чакыруны кабул итеп:

- Бигрәк бәләкәйсең, монда нишләп йөрисең? - диде.

Сөмбел күзләрен аера алмыйча:

- Мин монда торам, балалар бакчасында эшлим, - дип җавап бирде.

- Миңа калса, синең үзеңә няня кирәк, бигрәк бәләкәйсең бит.

Көй беткәч, егет аны урынына озатып куйды, ә икенче музыка башлануга, үзе биюгә чакырды.

Сөмбелнең авылдаш егете:

-Сөмбел, аңардан озыны юк идеме, кендегенә борының белән төртелеп йөрисең бит, - дип көлде.

Сөмбел оялудан ни әйтергә дә белмәде, җавап эзләгәнче, озак та уйламый, биек үкчәсе белән аның аягына китереп басты. Тегесе авыртудан кычкырып ук куйды. Озын буйлы егет:

- Менә шулай, дустым, кечкенәләрне рәнҗетергә ярамый, - дип көлде дә Сөмбелне читкәрәк тартты.

- Молодец, үзеңне кыерсыттырмыйсың. Алайса, син Сөмбел буласың, ә мин - Булат абыең.

Сөмбел күтәрелеп аның күзләренә карады, алар шундый матур итеп елмаялар иде, тик бу юлы нишләптер Сөмбелнең ачуын китерделәр.

- Кыерсытсаң, синекенә дә басармын. Миңа унсигез тула инде.

- Алайса ипи аз ашагансың, үсми кал¬гансың.

- Ипи түгел, әпәй. Аннан, кызлар шулай бәләкәй булырга тиеш. Кеше егерме биш яшенә кадәр үсә, диләр, шулай булгач, әле мин дә үсәрмен.

Менә шул көннән башлап алар аерылышмадылар. Булат кебек егет куенында җылы, рәхәт иде Сөмбелгә...

Сөмбел үзе сөйли, үзе көлә; аңа ияреп, йомшак кына матур тавыш белән, башын кыек салып, Булат та көлә: әллә аның сөйләгән сүзеннән, әллә шушы кечкенә карлыгачның бәхетле очынуыннан...

Учалы - район үзәге, үзенә күрә уртача зурлыктагы шәһәр, монда тирә-яктагы авыллардан яшьләр бик күп. Сөмбел дә шул яшьләр арасында кайнашып яши. Ял көннәрендә кич белән танцылар, уеннар була, тик кыз ял көннәрен яратмый. Җомга кич сөйгәне белән аерылышып, икесе ике якка үз авылларына кайтып китәләр. Ял көннәрен көч-хәл белән үткәреп, сагынышып, ашкынып яңадан шәһәргә киләләр. Менә соңгы вакытта әллә ни булды. Гел башы авырта, күңеле болгана: үткән атнада автобуста көч-хәл белән килеп җитте. Җитмәсә, башы әйләнә башлады. Менә бүген дә, эштән кайтып барганда, аяк астында җир убылгандай булды, бер коймага гына сөялеп калды. «Йә Ходай, бу ни инде, тизрәк кайтып җитәргә кирәк, соңгы рейска соңга калам бит», - дип, Сөмбел кызу-кызу атлый башлады. Ул тулай торакка кайтып җиткәндә, яшьләр инде вокзалга ашыгалар иде. Үз бүлмәсенә керү белән, аның артыннан Булаты да килеп җитте.

- Әйдә, тиз бул, бөтен кеше китеп бетте бит, нишләп соңладың? - диде ул.

- Булат җаным, миңа әллә ни булды, чирлим бугай, бер хәлем юк, гел башым әйләнә, күңелем болгана, көчкә кайтып җиттем. Автобуска якын барырга да куркам, килгәндә дә косып оятка калдым. Ничек кайтып җитәрмен?

Бу сүзләрне ишеткәч, Булат тынсыз калып, аның ап-ак йөзенә карады. Кичә дә: «Нишләп кәефе юк икән?» - дип уйлап куйган иде, гел көләч йөзле Сөмбел соңгы араларда шым гына йөри башлады шул. Булат сәгатенә карады да:

- Соңга калабыз, әйдә, тизрәк җыен, юлда сөйләшербез әле, - диде.

Алар йөгерә-йөгерә килеп җиткәндә, автобус шыгрым тулган иде. Булат Сөмбелне этеп-төртеп дигәндәй кертте дә, автобус ишеге ябылуга, үз авылы автобусына соңгы кеше булып кереп басты. Кысылып кайта-кайта, кабат кызны исенә төшерде: «Мине ир кеше була торып та кысып бетерделәр, ә ул кечкенә Сөмбелне, мескенемне, бөтенләй камыр итәрләр. Тукта, нишләп косам, чирлим, диде соң әле?» Кинәт күңелен куркыныч уй кисеп узды. «Юк, юк, булмас», - диде ул үзалдына. Өч ай элек кызуланып китеп, бер тапкыр якынлык кылганнар иде. Сөмбел: «Башка алай итмик, яхшы түгел, без бит әле өйләнешмәгән», - дигәч, ул аңа кагылмады.

Аларның яшь арасы дүрт ел гына булса да, Булат Сөмбелдән олырак күренә иде. Чөнки Сөмбелнең кечкенә буе, нечкә биле, кыска чәче, һәрвакыт гәүдәсенә килешеп торган кыска итәге уналты яшьлек укучы кыз кебек күрсәтә иде. Кызда әллә нинди яшерен сөйкемлелек бар, кыйгач кашлы шаян күзләр һәрвакыт елмаеп тора кебек; ул көлгәндә, аның күзләре дә көлә.

«Ул әле бала гына бит, Алла сакласын». Башына килгән уйдан Булат үзе дә куркып куйды, шул уйларына чумып, кайтып җиткәнен дә сизми калды.

- Инде курчагы белән бергә торып калды, ахры, дигән идем, кайткансың икән. Исәнме, абый.

Бу аның энесе - Байрас. Аралары ике яшь булса да, гәүдәгә бериш һәм бик охшашлар иде алар. Икесе дә озын буйлы, киң җилкәле, куе чәчле, сөрмәле зәңгәр күзле; эчеп-тартып йөрмиләр, эшчән, төпле гаиләдән. Алар авылның беренче егетләре исәбендә тора, яшерен гашыйк булучылар да күп иде үзләренә.

- Ә, синмени, сәлам, - диде ул энесенә.

- Нәрсә уйга чумдың? Клубка концерт килгән, ди, чыгабызмы? Автобуста Сәрия белән чибәр генә кунак кызлары да кайткан, чыгып, берәрсен тотып калырга кирәк, - дип көлде энесе.

-Сиңа тотарга гына булсын, - диде Булат һаман үз уйларыннан арына алмыйча. - Кайткан бер кунак кызын озатасың, берсе белән йөрмисең, бөтен авыл кызын озатып чыктың бит инде.

- Соң, абый, синеке кебек курчак очраса, бәлки мин дә туктар идем, юк бит. Тик сиңа да җитми, һаман ике көймәнең койрыгын тотарга тырышасың әле. Бүген тагын тегендә китәсеңме?

- Белмим, бәлки, китәрмен дә...

Алар кайтып кергәндә, әнисе кичке аш өлгертеп йөри иде. Өйдә аларның тугыз яшьлек энеләре Әлфис бар, ул бөтен өйнең хуҗасы да, күз өстендәге кашы да. Аңардан яхшырак яшәгән кеше юк: барысы да яраталар, иркәлиләр, гомумән, бу өйне Әлфистән башка күзалдына да китерү мөмкин түгел. Абыйлары кайту аның өчен олы бәйрәм. Алар аны Әлфис-Әлфис, әфлисун дип үрти, үзләре һәрчак берәр тәмле әйбер алып кайта. Энеләре аптырап калмый:

- Көлегез, көл, мин үскәч көрәшче булам, батыр булам, күрсәтермен әле мин сезгә әфлисунны, - ди.

Чынлап та, бу - көрәшче, батырлар гаиләсе. Әтиләре Шәүкәт абзый да элек көрәшче булган, яшь чакта беркемгә дә бил бирмәгән, хәзер менә Байрас улы да көрәш мәйданының күрке булып бара. Булатның гына исе китми, табигате белән йомшагракмы шунда... Көрәшкә бер генә чыгып карады, кызыгын тапмады. Ә менә Байрас тәмен белә: башта мәйдан уртасына чыгып, киң җилкәләрен селкетеп, бөтен мускулларын уйнатып ала. Аңа көрәш уен гына; көрәшкәнче бөтен хатын-кыз халкын үзенә борып куя, ул көрәшкәндә көрәш мәйданының тирә-ягы күбрәк хатын-кыз була.

Кечкенә Әлфиснең дә хыялы көрәшче булу иде.

Әтиләре малларны карап кергәч, алар, әзмәвердәй өч ир һәм Әлфис, җыелышып, өстәл янына кичке ашка утырдылар. Әниләре Гөлфия апа балаларына сокланып карап утырды. «Ходай кыз насыйп итмәде шул, өчесе дә малай бул¬ды. Ярар инде, Ходай яхшы килен бирсен, уллары бик акыллы. Насыйп булса, бәлки быел Булаты өйләнеп тә куяр әле. Өйләнәм дисә, бүгеннән туй ясарлык мал-мөлкәтләре бар. Аталары эчми-тартмый, бар тапканын өйгә алып кайта, шуңа һәрвакыт муллык белән яшиләр».

Ашап туйгач, уллары әниләренә рәхмәт әйтеп, үз йомышлары белән таралды. Булат арлы-бирле йөренгәләде дә:

- Әти, матайның бензины бармы? Барып кайтасы җир бар иде, - дип сорап куйды.

- Соң, бардыр, мин бит ат белән йөрим, атка бензин кирәкми.

- Алайса, мин әйләнеп кайтыйм әле, - дип чыгып китте.

Байрас абыйсының тагын теге авылга китүен аңлады, Булатның анда да кемедер бар иде, тик әле аның күргәне юк. Байраска Сөмбел бик тә ошый иде, ул елмайса, дөньялар яктырып китә, көлсә, кыңгырау чылтырагандай тоела, әллә кайсы ягы белән кыз үзенә җәлеп итә. Абыйсы янына тулай торакка килеп, аны күрми китсә, юкка гына килгән төсле тоела. Әйе, абыйсы аңардан алда өлгергән. Карарбыз инде, кайсына өйләнер. Бәлки бусына өйләнер дә, Сөмбел миңа калыр дип, үзен-үзе өметләндереп, нидер көйли-көйли клубка чыгарга җыенганда, янына әнисе керде, һич көтмәгәндә:

- Улым, синнән сер итеп кенә бернәрсә сорыйм әле. Абыең кайткан саен теге авылга чаба, әллә өйләнергә исәбе бармы? Синнән сере юктыр бит, ары-бире уйласа, итәк-чабуны җыештыра торыйк, дим. Улым, синең ул кызны күргәнең бармы соң? - дип сүз башлады.

- Белмим шул, әни, андый хәбәрем юк. Аннан бит абыйның йөргән кызлары икәү, кайсын сайларга да белми бугай. Кайчан сайлар, шулчак өйләнер.

- Тукта әле, улым, ничек инде икәү?

- Шулай, икәү: берсе тегендә, берсе монда; берсе көндәлек, икенчесе ял белән бәйрәмдә.

- Улым, алай ярамас, килешмәгәнне, кеше баласын харап итә күрмәгез. Теге көндәлек дигәнең ничегрәк соң, ямьсезме әллә, аламамы, бәлки җилбәзәктер?

- Улмы? Әни, беләсеңме, ул, - дип, Байрас бераз уйланып торды, - ул ай янында балкып торган кечкенә йолдызга охшаган, үзе кечкенә, үзе гел елмаеп тора.

- Соң, шулай булгач, абыең ник тагын бусының башын әйләндерә?

- Әни, ерактагы кояш ныграк җылыта, шуны да белмисеңмени? Ярый, мин китим, кунак кызларын бүлешеп бетерерләр алайса.

- Улым, тәртипле генә йөр, кунак кызлары дип, үзебезнең авыл кызлары да начар түгел, күзеңне ачып кара.

Булат өйдән чыгып киткәндә, кичке тугыз, Фәридәләргә килеп җиткәндә, төнге унбер тулган иде инде. Утын кабызып, өч тапкыр сигнал бирде. Күпмедер торгач, капкадан берәү чыкты, якынрак килеп җиткәч кенә таныды Булат, бу Фәридәнең сеңлесе иде.

- Апа кайтмады, Булат абый. Киләсе атнага, минем туган көнгә кайта.

Шимбә көнне кил, яшьләр җыелышып утырабыз, сине дә чакырам. Ярый, саубул, салкын алайса, - диде дә кире йөгерде.

Булатның кырык чакрым җил куып килүе юкка гына булды. Фәридәне инде ике атна күргәне юк, ул Златоуст шәһәрендә эшли. Элек Булат та шунда эшләгән иде. Булат кайтты, ә кыз «өйләнешкәч кайтырмын» дип калды, менә хәзер ике арада җил куып йөрергә туры килә. Фәридәне бик ярата шул, зифа буйлы, төз гәүдәле, озын куе чәчле, бик чибәр һәм бик горур, аның алдында артык сүз ычкындырырга да курка. Аның өчен Фәридә - күктәге буй җитмәс йолдыз. Сөмбел белән чагыштырсаң, җир белән күк арасы. Сөмбел һәрвакыт көлүе-шаяруы белән һавада очкан күбәләк кебек булса, Фәридә аз сүзле, һәр әйткән сүзен уйлап, салмак кына сөйләшә, үпкәләсә, айлар буе сөйләшми торган гадәте бар, бик горур ул. Шуңа да Булат аны үпкәләтүдән курка, сүзен чамалап, ярарга тырышып сөйли. Шундый акыллы, чибәр кызның аңа каравына ышанып та бетә алмый, ул аны сайлавына бик горурлана. Фәридәгә өйләнсә, егетләрнең борынына чиртәчәк, андый горур сылулар һәркемгә дә эләкми шул.

Булат төн уртасында гына кайтып ятты, энесе әле кайтмаган иде. Ятуга йоклап та китте. Төне буе Сөмбел белән саташып чыкты: ул яр башына баскан да аска карап тора, кулында ак төргәк, төргәктә яшь бала, шул бала үзәк өзгеч итеп елый, ә Сөмбел упкынга сикерергә җыена. Булат, аны туктатырга теләп, ярга каршы йөгерә, бөтен көченә «тукта-тукта» дип кычкыра, тик нитер тавышы чыкмый. Шулчак энесе селкеткәнгә уянып китте.

- Саташасың, ахры, борылып ят, үтерәләрмени, ыңгырашасың, Сөмбелне чакырасың, - дип, абыйсын уятты да кире урынына барып ятты.

Булат шабыр тиргә батты, курку катыш әллә нинди хисләр кичерде.

Әгәр дә аның шиге дөрес булса, Алла сакласын, уйларга да куркыныч, бер кылган гөнаһ өчен гомер буе газап чигәргә туры килсә нишләрсең? Йә Хо¬дай, үзең сакла...

Бу ике көн үтмичә җанга тиде, әллә никадәр эш эшләделәр, тик көннәр генә бик әкрен узды. Шимбә үтеп, якшәмбе җиткәч, китәр вакытны санап сәгать үтте, аның тизрәк Сөмбелне күреп, шикләренә ачыклык кертәсе килде. Ул әле бала гына, берни аңламый, ахры, әгәр әнисе белсә, бетте баш, йә өйләндереп, йә утыртып куяр...

Булат тулай торакка килеп җитү белән Сөмбел бүлмәсенә кереп чыкты, тик кыз килмәгән иде. Сөмбелнең авылдашы Мансур очрап:

- Сәлам, килдең дәме?! Кара әле, синең кечкенә курчагың вокзал эскәмиясендә утырып калды, әллә чирли инде, йөзе ап-ак, килгәндә дә ишек төбендә генә басып килде. Элек бертуктаусыз сыерчык кебек сайрап-көлеп тора иде, ә хәзер эндәшми дә, чирли, ахры, ул, - дип үтеп китте.

Булат, Мансурны тыңлап та бетермичә, тиз генә вокзалга йөгерде. Вокзал тулай тораktан ерак түгел, аны каеннар гына каплап тора. Каенны кочаклап торган Сөмбелне ул ерактан ук күреп алды.

- Сөмбел, ни булды? Хәлең ничек?

- Юк, карама миңа, әллә ни булды. Бертуктамый косасым килә, башым әйләнә, көч-хәл белән генә килеп җиттем. Әллә нинди чир эләкте, үлмәсәм инде.

- Кара әле миңа, Сөмбел, кайчан башланды бу чирең, хәтерлисеңме?

- Әллә, бер айлап бар бугай инде. Әни иртәгә больницага ашказанын тикшертергә барырга кушты, бик ябыккансың, ди.

Димәк, Булатның шиге дөрес булды: «Да, иштең ишәк чумарын, хәзер ничек аңлатырга инде бу балага... Их, бетте башларыбыз».

- Әйдә, менә монда утырыйк әле.

Алар ерак түгел бер эскәмиягә барып утырдылар.

- Мин синең чиреңнең сәбәбен беләм бугай... Әйтсәм куркырсың инде, хәер, мин үзем дә куркам... Син бит хатын-кыз, үзең дә аңларга тиешсең.

Сөмбел, аптырап, аңа карап утыра бирде. Ә Булат, ничек сүз башларга белмичә, тирләп-пеште, ике кулына урын таба алмады.

- Ни булды? Битеңә тир бәреп чыкты, миндә берәр начар, йогышлы чирме, әл¬лә мин үләмме? Син каян беләсең миндә нинди чир икәнен?

- И сабыем минем, бигрәк баласың шул әле син. Юк, үлмисең. Син авырга узгансың, бу чир түгел, аннан үлмиләр, йә бала табалар, йә вакытыннан алда алдырып котылалар.

Гаҗәпләнүдән Сөмбелнең күзләре түгәрәкләнде:

-Ничек? Кайдан? Син бит берни булмый, дидең...

Ул торып басты, аннары кинәт камыр кебек бөгелеп төште. Булат аны тотып өлгерде, ипләп кенә алдына утыртты.

-Курыкма, берәр нәрсә уйлап табарбыз.

Сөмбел ни шатланырга, ни кайгырырга белмәде.

- Булат җаным, мин чирлим дип курыккан идем, балага узу - үзе бер бәхет бит ул. Безгә беләнә башлаганчы өйләнешергә кирәк, тукта, кайчан булды соң, син хәтерләмисеңме? Йә Ходай, башымда эшләми, балага шулай тиз узалар микәнни, башка сыймый торган хәл. Ә ул кайчан туачак, малаймы, кызмы икән?! Булат дим, Булат, ник дәшмисең?

- Тыңла әле, Сөмбел, мин болай булуын теләмәгән идем, аңлыйсыңмы, теләмәгән идем. Беләм, мин гаепле синең алда, тик син дә мине аңларга тырыш, мин сиңа өйләнә алмыйм. Мин башканы яратам... Минем ярәшкән, яраткан кешем бар. Аңлыйсыңмы, мин сиңа өйләнә алмыйм, булдыра алсаң, гафу ит, кичер мине. Кирәкми миңа ул бала. Без ялгыштык, икебез дә ялгыштык. Әле соң түгел, тыңла мине...

Ул, Сөмбелнең таш кебек катып калган ап-ак йөзен күреп, туктап калды. Кызның кыска чәчләрен көзге җил тузгытты, ләкин йөзендә бер үзгәреш сизелмәде, арттан пычак тыгып, җанын алгандай селкенмичә тик утыра бирде.

Ул, Сөмбелнең кычкырып елап җибәрүеннән куркыпмы, үзе дә аңламыйча, ике кулы белән колагын каплады, кызны ничек юатырга да белмәде, күзеннән кайнар яшь тамчылары бәреп чыкты... Шул халәттә күпме утыргандыр, өши башлады.

- Йә, ярый, әйдә, кайтыйк.

Ул борылганда, янында беркем дә юк, бары Сөмбелнең сумкасы гына утырып калган иде. Егет як-ягына каранды, һич¬кем күренмәде. Караңгы да төшеп килә.

Булат, тулай торакка кайтып, өс киемнәрен алыштырды да, Сөмбелнең сумкасын бирергә бишенче катка менеп китте, тик ишек ачучы булмады. «Кирәк булса, үзе кереп алыр», - дип, бүлмәсенә төшеп, йокларга ятты. Иртән торганда да сумка урынында тора иде. «Ярар, кич эштән соң кертермен әле», - дип, эшкә китте. Кич күнеккән гадәт буенча Сөмбелләр бүлмәсенә күтәрелде. Ишекне Сөмбелнең бүлмәдәш кызлары ачты.

- О, җизни килгән, апа гына нишләптер җомгадан бирле күренми, әллә авылыңа алып киттеңме?

Булат аптырап калды.

- Ничек юк? Авылдан кичә килде бит ул.

- Без күрмәдек, килмәде. Кичә дә, бүген дә юк. Эшендә булдымы икән соң?

Булат ни әйтергә белми торды да:

- Кайтса, безгә керсен әле, - дип пошаманга калып төшеп китте.

Кич буе Сөмбелне көтсә дә, бушка булды, кыз күренмәде. Булат атна буе һәр кич алар бүлмәсенә кереп йөрде, Сөмбел кайтмады. Ул ни уйларга белмәде, үзе белән берәр хәл кылмасын дип курка калды, теге күргән төше ба¬шыннан чыкмады. Бәлки барысын да аңлагандыр, акылсыз түгел бит, дип, үзен-үзе юатты.

**(Дәвамы бар).**

**ООО «Немецкие оконные изделия»**



1. Заводское производство.
2. Гарантия качества.
3. Короткие сроки.
4. Установка входных и межкомнатных дверей.
5. Выезд на замер бесплатно.

При заказе 3 окон - жалюзи в подарок
При заказе 4 окон - дверь входная в подарок.
При заказе 5 окон - шестое окно в подарок.

**Рассрочка и скидки!!!**

*Условия акции по тел.: 89020040102; 89374588644; 89278018665.*

*Супер акция - окно из профиля 70 мм. по цене окна из профиля 58 мм.*



● Окна от производителя
+ комплектующие
● Двери «Бульдорс»
● Натяжные потолки
(от 240 руб./в.м)

Телефоны: 88422(651832), 89041823507, 89374550649.

Фотограф
на свадьбу, никях, девичник, выпускной, праздник.
Т.: 8-927-801-38-11- Наталья.






**Срочно! Недорого!** В р.п. Старая Кулатка по ул. Тукая, 75 продается дом со всеми удобствами. Телефон: 89278233601.

В р.п. Старая Кулатка по ул. Куйбышева 26, продается трехкомнатная квартира, общей площадью 53 кв.м. Имеется все для комфортного проживания. Цена договорная. Телефон: 89272712598.

В ООО «ТАН» требуются водители категории «С» и «Е». Желательно с картой водителя на тахограф. Адрес организации: р.п. Старая Кулатка, ул. Красногрвадейская, д.18. Телефон для справок: 2 – 27 – 23.

В р.п. Старая Кулатка по ул Мусы Джалиля продается дом площадью 70 кв.м., с земельным участком – 1200 кв.м. Со всеми удоствами, с ремонтом. Имеются: гараж, баня, огород, сараи, погреб – все в отличном состоянии. Цена договорная. Рассмотрим варианты обмена на квартиру в микрорайоне М. Джалиля. Возможна продажа на на различные жилищные сертификаты сертификаты. Телефон: 8 - 927 – 986 – 62 - 55.

**ПЛАСТИКОВЫЕ ОКНА**
**от производителя.**
**НАТЯЖНЫЕ ПОТОЛКИ НЕДОРОГО.**
**РАССРОЧКА.**
**Просто позвони.**
**Телефон: 89272125484.**




Салон бытовых услуг р.п. Старая Кулатка
с 18 мая проводит Дни открытых дверей.
Наших клиентов ждут скидки на
- Реставрацию подушек;
- Оформление торжеств воздушными шарами;
- Услуги квалифицированного парикмахера (стрижка, покраска, химическая завивка, мелирование и нарядные прически!)
Ждем ВАС!!! Телефон для справок: 8-929-796-73-88.



**Услуги эвакуатора.**

**Выкуп аварийных автомобилей.**

**☎Телефон: 89278229696.**

**23 Мая с 11.30 ч. до 12.30 ч.**
**Приглашаем за покупками в р.п. Старая Кулатка**
**На рынке будут продаваться:**

1. Автоматические инкубаторы с гигрометром – от 3300 руб. Переходник с 12В на 220В – 1100 руб. Прибор термометр - гигрометр – 400 руб.
2. Ножи – 1000 руб. Машинки для стрижки овец - 6200 руб. Отпугиватель грызунов – 1500 руб.
3. Парники, теплицы с укрывной пленкой (2м*3м*6м) – 700 руб., 5500 руб.
4. Электровелосипед: скорость до 25 км/ч, не нужно прав, запас хода – 20 км - 28000 руб.
5. Чудо-лопата, 2 сотки за час без боли в спине - 1300 руб. Автоматические тонометры - 1600 руб.
6. Растворитель для уличных туалетов, септиков. Очиститель дымоходов - 300 руб.
7. Распродажа бензопил, бензокос – 4900 руб., 5100 руб. Доильная установка – 25000 руб.
8. Печи для бани с баком из нержавейки - 15800 руб.
9. Измельчитель зерна, травы, корнеплодов – от 2400 руб. Молоточки, сито для зернодробилок – 120 руб.
10. Электродвигатели мощность 1,2-2,2 кВт к зернодробилкам, циркуляркам , ножи, сито, щетки - 1200 руб., 6000 руб., 60руб.
11. Кормоцех: кулачковый измельчитель зерна 700 кг/ч кукурузных початков, корнеплодов, сена (можно сделать для гранулятора) - 15600 руб.
12. Комнатные биотуалеты – для больных, пожилых, детей (герметичные, компактные, не требуют канализации) – 5200 руб.
13. Сочные консервы за 20 минут в нашем автоклаве (30л) – 7500 руб.
14. Поглотитель влаги в помещении, подвалах - 100 руб. Коптилки для рыбы и мяса - 2200 руб.
15. Электростамеска ( дерево, железо), реноватор – многофункциональный прибор для ремонта – 1500 руб.
16. Жарочный шкаф (духовка) с термостатом и таймером 20л., 33л. – 2100 руб., 3300 руб.
17. Сборно-металлический гараж из профнастила (3,5м*5,1м*2,5м) - 38000 руб.
18. Мотокультиватор (6,5 л.с), мотоблок – 18000 руб., 25000 руб.
19. Двигатели – 6500 руб. Плуги, окучники, телеги к мотоблоку - 15000 руб.
20. Всесезонный тентовый гараж, домик для охотников, механизаторов, склад для хранения материалов (3,7м*6,1м*2,5м) - 21000 руб.

**Контактный телефон: 8(909)146-33-00.**

# Көтмәгәндә килә, ә менә куып чыгару...

Татар телендә аны аю чикерткә яки бозаубаш, дип атыйлар, русча тәрҗемәсе исә –медведка. Әлеге бөҗәктән иза чиккән бакчачылар аның никадәр зыян салуын белә. Ул – бакчаның иң зур дошманы, дип әйтсәк тә була.

Беренче карашка, ул фантастик кинофильмнарда күрсәтелә торган монстрга охшаган: иләмсез зур башы, мыеклар, тәне көрән төстәге каты кабырчык белән капланган, алгы аяклары – көчле, корсак артында – үсентеләр, зур канатлары бер бакчадан икенчесенә күчәргә ярдәм итә. Аю чикерткә 5-6 сантиметрга кадәр үсә. Ана бөҗәк 100дән артык йомырка сала. Бакчага кереп оялаган бу корткычны вакытында күреп алмасагыз, әйбәт уңыш җыю авыр булыр.

Аю чикерткә яшь үлән, тамыр, бүлбе (клубень) ярата. Караулы, тәртипкә салынган бакчаларда яшәүне хуп күрә. Ә менә чүп үләнен ашамый. Кәбестә, бәрәңге, баклажан, редис, чөгендер, помидор, борыч, петрушка, күп кенә гөлләр – аннан зыян күрүче культуралар байтак. Бөҗәк куак, агачларның тамырларын да калдырмый. Казыган оялары бик озын булып сузыла һәм бакчаның зур мәйданын ала.

Аю чикерткәне бетерү авыр, әмма була торган эш. Тәҗрибәле бакчачылар аларга тозак салырга киңәш итә. Шуларның берничәсе турында язабыз.

Аю чикерткә кышны җир астында үткәрә. Шуңа күрә аны суыта төшкәч, көзен яки иртә язда юк



итәргә кирәк. Бу вакытта ул әле үрчемәгән була.

Иң нәтиҗәле тозакларның берсе – тирес. Аю чикерткә җылы һәм йомшак урында кыш чыгарга тырыша. Моның өчен киңлеге, буе, биеклеге 50 сантиметр булган чокырлар казып, аны тирес белән тутырырга кирәк. Салкыннар килгәч, тиресне чокырлардан казып алып, бакча буйлап таратып чыгыгыз – бөҗәкләр өшеп үләчәк. Әгәр дә моны эшләргә өлгермәсәгез, тозакларны язын казып чыгарыгыз, алардагы йомыркаларны юк итегез.

Шулай ук, сыра тозагы уңай нәтиҗә бирә. 0,5 литрлы унлап пыяла банка яки шешәне, бакчада чокырлар казып, авызына кадәр күмеп куегыз, өчтән бер өлешен сыра белән тутырыгыз. 1,5 сантиметр ара калдырып, тозакны такта белән каплап куегыз. Шунда төшкән бөҗәкләрне чыгарып яндырыгыз.

Сабынлы су да ярдәмгә килә ала. Бер чиләк суга хуҗалык (10-20гр) яки сыек сабын (50г) кирәк булыр. Аю чикерткә өннәрен табып, сабынлы суны салып чыгыгыз. Әмма күп сабын салырга тырышмагыз, җир астында үсемлекләрнең тамыры барын да онытмагыз.

Өн эченә үсемлек мае салып, шлангтан салкын су өстәгез. Бөҗәкләр майлы суны яратмый, алар я үлә, я тышка чыгачак.

Кибетләрдә аю чикерткәгә каршы күп кенә химик препаратлар сатыла: Гром, Фенаксин Плюс, Медвегон, Гризли, Медветокс, Рембек. Аларны дөрес итеп кулланганда, бөҗәкләрнең 60-90 проценты үлә. Зыян итүчеләрнең өннәрен табып, һәрберсенә 3-4 гранула салып чыгыгыз, куак яннарын һәм тирес тирәсен онытмагыз. Кошлар ашамасын өчен, агу өстенә аз гына туфрак салыгыз. Игътибар! Аның белән эш иткәндә, резин перчатка, респиратор яки медицина маскасы киегез. Эшне бетергәч, кулларны һәм битне сабын белән юыгыз, авызны чайкагыз.

Гомумән, һәр бакчачы бөҗәкләргә каршы профилактик эшләр алып барырга тиеш: көзен кипкән яфракларны, ботакларны, чүп-ләрне, уңыш калдыкларын җыярга, игътибар белән карап чыгарга һәм, әлбәттә, бакчаны казырга – җир астында булган бөҗәкләр салкында яши алмаячак.

Директор-баш редактор
М.С. МАСИЕВА.

Адрес редакции, издателя:
433940
р.п. Старая Кулатка
Ульяновской области,
ул. Куйбышева, 22.
ОАУ "Редакция газеты
"Кумяк кюч".

**Телефоннар:**
электрон адрес:
kumiakk@mail.ru
884(249)2-11-94-редактор, факс, бухгалтерия;
884(249)2-12-64 - журналистлар, реклама бүлеге, РИК операторлары.

**Индекс 54505.**
**Газетаны басарга кул кую вакыты:**
**график буенча - 16.00**
**фактта - 16.00**
**Тираж 2825**
**Заказ № 13/20**
**Распространяется по подписке.**

Газета отпечатана с готового оригинала-макета в ООО «Принт Хаус»
432071, г. Ульяновск, ул. Федерации, 15.

**Элемтә һәм масса - күләм коммуникацияләр сферасында күзәтү буенча Федераль служабның Ульяновск өлкә идарәсе 2014 елның 21 ноябрендә ПИ №ТУ73-00388 номерлы масса-күләм информация чарасын регистрацияләү таныклыгы белән регистрацияләнде.**
**Газета битләрендә урнаштырылган рекламалар һәм белдерүләр өчен редакция җаваплылык тотмый.**
**Мәкаләләрдә авторларның фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.**
**Хатлар, кульязмалар һәм рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.**